Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 20 (1436) 26 май 2023 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madani_zhomga

8

Аксубай районы Яңа Ибрай авылында туып-үскән генерал-майор Алмас Әдһәмовны искә алдылар.



12

Бизәнгечләре Лондон, Нью-Йорк аукционнарында сатыла торган Илгиз Фазылҗанов туган як табигатеннән илһам ала.

16

Милләтебезнең ике мөхтәрәм шәхесе – Гаяз Исхакый белән Габдрәшит Ибраһим арасында төрле яссылыктагы каршылыклар күзәтелгән.

Мәктәптә соңгы кыңгырау – Олы юлның башыдыр!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ринат Гобәйдуллинны искә алу кичәсендә композитор истәлегенә оештырылган төбәкара «Сердәш» фестивале җиңүчеләре бүләкләнде.
- «Былбыл» Санкт-Петербург татар халык театры дүртенче премьерасын чыгарды: шәһәрнең «Рыбацкий» мәдәният йортында «Сигез йөрәк сере» спектакле күрсәтелде.
- Омск өлкәсе Тәвриз районы имамы, махсус хәрби операциядә һәлак булган Руслан хәзрәт Вахитов үлгәннән соң Бөтендөнья татар конгрессының «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнде.
- Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Резеда Әхиярованың тормышына һәм иҗатына багышланган китап басылып чыкты.
- Арча районы Казанбаш мәктәбенә шушы мәктәптә укыган Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов исеме бирелүгә багышланган тантана булды.
- Казан федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр институтында яңа уку елыннан иске татар телен өйрәнүчеләр төркеме ачылачак.
- 27 май көнне кичке сәгать 6 да Камал театрының Шәрык клубында Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин иҗатына багышланган «Сылтама заманга...» әдәби-музыкаль кичә була.
- Дәүләт сынлы сәнгать музееның Заманча сәнгать галереясында «Урман» мәгърифәтчелек проекты ачылды.
- Татарстанның атказанган артисты, җырчы Зөфәр Сафин вафат булды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Рәфыйк МӨХӘММӘТШИН, Россия ислам институты ректоры:

«Безнең бакалавриатта 45 фән бар. Шуның 10 ысын гына татарча укыта алабыз, чөнки калганнарын татарча укытырлык укытучыларыбыз юк. Мәктәптә, югары уку йортында рус телендә белем алган педагогның татар теле кухня теленнән югары булмый. Без татар телендә укытуны мәҗбүр итсәк, белем бирү дәрәҗәсе мәчетләр каршындагы курслар кебек калачак. Югары уку йортында татарча укыту – ул Россия ислам институты проблемасы гына түгел, ә глобаль проблема».

СЫНАМЫШЛАР

26 майда черки күп булса, солы уңа; аз булса, печән дә, ашлык та уңмый ● 27 майда салкын булса, җәй салкын була; аяз булса – кыяр уңа; болытлы, салкынча булса, бу көнне чәчелгән кыяр уңмый. ● Яз көне урманда зәңгәр чәчәк күп булса, ашлыкны кырау алмас, карабодай бик уңар ● Тургай күп булса, печән уңар ● 1 июньдә яңгыр яуса, ай буе коры була; бу көнне кыяр чәчәләр.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 16 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 07 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **16 сәгать 51 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **19 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **3 июньдә 17 сәгать 10 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

29 май – әдәби тәрҗемәче Азалия Исмәгыйль кызы Бадюгинага 90 яшь (1933);

– Тел галиме, профессор Хәнисә Чавдат кызы Алишинага 70 яшь (1953);

– Шагыйрь Бикбулат Вәли улы Сөләймановның тууына 85 ел (1938–1991).

30 май – әдәбият тәнкыйтьчесе, шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мөдәррис Харис улы Вәлиевнең (Салих Маннапов) тууына 70 ел (1953–2020).

31 май – шагыйрь, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Мөхәммәт Хәбибулла улы Садриның (Садретдинов) тууына 110 ел (1913–1999).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Май-июньнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 26 май.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(27 май-4 июнь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

###ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген зөлкагдә аеның 6 нчы көне

КӨН КАДАГЫНА

Рифат КАЮМОВ

«Татар телен өйрәнүгә мотивация түбән»

Әгерҗе районы Иж-Буби авылында мәгърифәтче Бубилар исемендәге VIII төбәкара укулар узды. Туган телне өйрәнү мәсьәләләренә кагылган түгәрәк өстәл утырышында татар теле укытучылары, җәмәгать эшлеклеләре, мәгариф тармагы өчен җаваплы кайбер вазыйфаи затлар катнашты. Сөйләшү барышында актуальлеге югалмас кызыклы фикерләр яңгырады. Нинди дә булса уңышка ирешү өчен, мотивация кирәк. Телне өйрәнү турында фикер алышканда, мотивация беренче планга чыкты.

Илгиз Халиков, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе җитәкчесе:

– Беренче чиратта, татар телен туган тел буларак өйрәнергә мотивация булырга тиеш. Бүген мотивация бик түбән дәрәҗәдә. Бигрәк тә ата-аналарда. Балаларда алай ук түгел.

2018 елда мәгариф турында федераль законга үзгәреш кергәннән соң, ата-аналар туган телне гариза язып сайлый башлады. Алар «татар теле ни өчен кирәк?» дигән сорау бирсә, без аргументларны җиткерә белергә тиешбез.

Татар теле яшь буынга нәрсә бирә ала? Кемдер «туган телне саклау – ата-бабалардан килгән бурыч» дип аңлатырга мөмкин, ләкин аның белән генә яшьләрне кызыктырып булмый. Ул татар теленең гамәли кулланышта булуын, киләчәктә файдасын аңларга тиеш.

Соңгы ел эчендә күп кенә Европа дәүләтләре бездән йөз чөерде. Аларның моңарчы да безгә карата уңай сәясәт алып бармаганы билгеле иде. Россия Көнбатышка файдалы казылмалары белән генә кызыклы булды, дисәк, хата булмас. Бүген илебезнең төрки дөньясына таба борылуын күзәтәбез, ә татар теле – төрки халыклар гаиләсенең исемлегендә торган иң камил телләрнең берсе. Ата-аналар белән сөйләшкәндә, нәкъ шул тезисны җиткерергә кирәк.

Яшь буын вәкилләре арасында Европа телләренә тартылу көчле. Тиз вакыт арасында теге яки бу телне үзләштереп, шул илгә күчеп матур тормыш белән яшәргә хыяллану бар. Телләрне үзләштерү өчен теге яки бу тел вәкиле белән аралашу, тел мохите кирәк.

Шул ук Европа илләре арасында безнең ватандашларыбыз өчен иң популяр юнәлеш – Төркия. Билгеле, татар телен белсәң, төрек телен өйрәнергә җиңел, чөнки тел, мәдәният һәм дин якынлыгы бар. «Инвестиция климаты» дигән төшенчәгә килсәк, бүген иң күп товар алышу Төркия һәм Урта Азия илләре белән бара. Хәзер алар югары үсеш баскычына басты. Бүген төрки дөньяга телебез, мәдәниятебез һәм гореф-гадәтләребез аркылы җиңел керә алабыз.

Европа белән Азия кисешкән материкта яшәгәч, безгә электәннән ике якны да берләштерү миссиясе йөкләнгән. Без Азия илләре телләрен инкяр итәргә тиеш түгел. Ниһаять, шушы миссияне тормышка ашыру заманы килеп җитте.

2011 елда Казан федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр институтында «Төрки халыклар тарихы» һәм «Төрки халыклар сәясәте һәм икътисады» дигән 2 белгечлек барлыкка килде. Әлеге белгечлекләрдә уку тулысы белән республика бюджеты хисабына оештырыла. Шушы юнәлешләр буенча укыган белгечләргә эш бирүчеләр тарафыннан ихтыяҗ зур. Үз вакытында бу белгечлек программаларын булдыру үзен aклады. Бу белгечлеккә керү өчен төп шарт – татар телен белү. Мотивациягә? Әйе.

Татар телен белгән тәрбиячеләр балалар бакчаларында татар төркемнәрендә дә, рус төркемнәрендә дә эшли ала. Күп кенә оешмаларда ике телне камил белгән белгечләргә ихтыяҗ, хөрмәт зуррак, чөнки алар ике төрле аудитория белән эшли ала. Бу да – яхшы мотивация.

Хәзер икетеллелекне, күптеллелекне мактыйлар. Күптеллелек нәкъ татар теле белән рус телен белүдән башлана. Мин Башкортстанда тудым, татар телендә телем ачылды, рус мәктәбендә укыдым, татар телен укыдым һәм башкорт телен факультатив рәвештә өйрәндем. Мәктәптән соң, Башкортстанның Стәрлетамак дәүләт педагогия академиясенең татар һәм чуваш кафедрасын тәмамладым. Бүген дүрт милләт вәкиле белән аралаша алам.

Күптеллелек чит ил телләрен өйрәнүдән түгел, ә якын-тирәбездә яшәгән халыкларның телен белүдән башлана. Модага ияреп чит телләрен өйрәнеп тә, бик сирәкләр генә ул телләрне үзләштерә ала. Күпчелек ватандашларыбыз үз гомерендә бер тапкыр да Европа илләренә сәяхәт кылмаска мөмкин. Үзебезнең илебезне өйрәнеп, анда яшәгән халыкларның телләрен белү күпкә отышлырак күренә.

Галимнәр әйтүенчә, күбрәк телләр белгән кешенең баш мие яхшырак һәм тизрәк эшли. Баш миенә томография ясаганда да бу күренә икән. Ике һәм күп телләр белгән кешеләр арасында деменция чиренең (хәтер югалудан) интегүчеләр сирәк була, диләр. Бер генә тел белүчеләрнең баш мие иренеп эшли. Бу – «һавадан алган» сүзләр түгел. Бүгенге көндә Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Югары икътисад мәктәбенең Тел һәм баш мие үзәге арасында килешү төзелде. Әлеге үзәкнең тикшеренүләре нәкъ югарыда әйтелгән фикерләрне дәлилли.

Әби-бабаларыбызның хәтерләре 90 яшендә дә яхшы иде. Аның сәбәбе ярылып ята. Беренчедән, алар туган телендә аралашкан, рус телен белгән һәм Коръәнне гарәп телендә укыган.

Хәзер милли мәсьәләләрне фәнни яссылыкта хәл итәргә була. Байрак күтәрә торган заманнар үтте. Ул вакытта, бәлки, байрагы да кирәк булгандыр. Мәдрәсәләребез тарихына күз салсак, аларның бөтенесендә дөньяви фәннәргә һәм татар, гарәп, фарсы телләрен белүгә игътибар нык булган. Бүген дә безгә татар теле аркылы төрки дөнья белән якынаю мөмкинлеген аңларга кирәк. Әлбәттә, җыр-моң да, милли кием дә кирәк, ләкин алар заманча булырга тиеш.

Без Иж-Буби музеен карап чыктык. Мәдрәсә шәкертләре дөньяви фәннәргә, телләрне өйрәнүгә тартылган. Милләтнең көче алдынгы карашта булган. Безгә дә алдынгы караш һәм акыл белән эш итү кадерле.

Тәлгать Әхмәдишин, җәмәгать эшлеклесе:

– Баланы татар телендә укыту өчен мотивация, әлбәттә, кирәк, ләкин без, күпме генә пропаганда алып барсак та, моңа ирешә алмадык. Минемчә, төп проблема – укытучыларда. Фәнне татарча укытуга, беренче чиратта, укытучылар каршы бит. Хәтта авыл укытучылары моңа аяк терәп каршы тора. Аларга бик күп терминнарны тәрҗемә итәргә кирәк, ә бу эшкә өстәмә акча түләнми. Ата-ана баласын татарча укытырга теләсә дә, укытучылар каршы киләчәк. Бу проблеманы ничек хәл итәргә?

Илгиз Халиков:

– Андый проблема бар, килешәм. Татар телендә укыткан өчен өстәмә акча каралмаган шул. Без укытучыларны грантлар ярдәмендә кызыксындыра алабыз. Моңарчы «Оста мөгаллим» дигән грант эшләп килде. Кызганыч, әлегә ул туктатылып тора. Күп кенә финанслау мәсьәләләрен хәл итү, билгеле сәбәпләр аркасында, кичектерелә. Укытучының мотивациясен арттыруда да безгә уртак фикер табу сорала. Һөнәри бәйгеләр оештырабыз. Аларның приз фонды да әйбәт, ләкин җиңүче берәү генә була, ә бүләкне кимендә 10 кешегә бирергә кирәк.

Тәлгать Әхмәдишин:

– Балалар бакчаларына икетеллелек керттеләр. Янәсе, тәрбияче атнаның 2 көнендә – татарча, 3 көнендә русча сөйләргә тиеш. Шушы ике теллелек дип, татар балаларын рус теллегә әверелдермибезме? Балалар болай да үзара русча сөйләшә бит.

Илгиз Халиков:

– Монда күп әйбер методикадан тора. Теге яки бу телне өйрәнүдә көннәргә бүлү турында сүз бармый. Киресенчә, ике телне дә бер күләмдә бирү, ягъни билингвизм принципларына таяну отышлы.

Тәлгать Әхмәдишин:

– Татар телендә укытуны административ чаралар белән арттырып булмыймы?

Илгиз Халиков:

– Административ чараларны бик сак кулланырга кирәк, чөнки ныграк басым ясаган саен, кире эффект булуы ихтимал. Иң элек, телгә карата мотивация, аның кулланылышы даирәсен киңәйтү һәм функциональлеген арттыру мәсьәләсе тора.



Рафик Таһиров, Әлмәт театры актеры, Татарстанның халык артисты:

– Яһүдләр үзләренең үлгән, борынгы иврит телен кайтарды, ә без үз телебезне киләксенмибез. Без нык наданландык. Совет чоры шулай эшләдеме, әллә соңгы 30 елда шушы хәлгә калдыкмы?.. Монда милли җанлы кешеләр җыелган. Без барыбыз да туган телебезнең язмышы өчен борчылабыз. Һәрберебез кешеләр белән сөйләшеп, унысында булса да милли уззаң уята алсак, алга таба хәрәкәт итәргә буладыр. Булмастай эш түгел инде бу. Аның киләчәге булыр.

Илгиз Халиков:

– Гамәли адымнар булырга тиеш. 90нчы елларда милли хәрәкәт башында торган абыйапаларыбыз, фатирлар буенча йөреп, халыкның милли үзаңын уятып җибәрде. Миңа ул чакта 10 яшьләр иде. Бу эшне яхшы хәтерлим.

Кулдан килгән кадәр һәрберебез аңлату эшен алып барыйк. Мин үземнең вазыйфада, сез – үз вазыйфагызда. Конструктив тәнкыйть булсын, ләкин бер-беребезне батырмыйк.

intertat.tatar

Мәк җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

ИЗГЕ БОЛГАР ҮЗЕНӘ ТАРТА

Узган атна Татарстанда ислам дине белән бәйле зур чараларга бай булды: 18-20 май көннәрендә «Казан Экспо» дигән халыкара күргәзмәләр үзәге мәйданнарында колачлы чара – «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2023» дигән XIV халыкара икътисад форумы узды һәм, аның делегатлары 21 майда Болгарга күчеп, биредә һәр елны инде традиция рәвешендә үткәрелә торган «Изге Болгар җыены»нда да катнашты. Шуңа быел инде ул «KazanForum 2023» нең мәдәни программасы үзәгенә дә әверелде кебек. Ә Җыен алдыннан Казанда янә бер традицион чара – татар милләтеннән булган дин әһелләренең «Милли тормыш һәм дин» дигән XIII Бөтенроссия форумы (аның пленар утырышы) да үтте. Әлбәттә, аның делегатлары да «Изге Болгар җыены»нда катнашты. Узган атнада Казанда Russia Halal Market дигән хәләл ярминкә дә эшли башлады. Максаты – Россиядә хәләл индустриясе популярлаштыру. Сүз инде бу очракта хәләл ризык турында гына түгел, ә хәләл сәнәгать төркеме, медицина, туризм, мәгариф, финанс эшләре һәм инвестицияләр турында да бара. Аңлашылганча, бу чорда Татарстанда әлеге вакыйгалар белән бәйле күп кенә мәдәни һ.б. чаралар да үткәрелде.

Ә сәхифәбездә бу юлы сүз күбрәк төп чара – «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2023» дигән XIV халыкара икътисад форумы тирәсендә булыр. Чөнки ул бүген Россия белән ислам дөньясы арасында икътисади багланышларның төп мәйданчыгы да булып тора. Искә төшереп үтик, Халыкара икътисад форумы Казанда тәүге тапкыр 2009 елда үтте һәм шуннан бирле ул һәр елны оештырылып килә. Быел гыйнвар урталарында Россия Президенты В.Путин, илдәге икътисади вәзгыятьне исәпкә алып булса кирәк, аның исемен үзенең указы белән KazanForum дип үзгәртте һәм аңа федераль статус та бирде. Оештыру комитетын исә Россия хөкүмәте вице-премьеры М.Хөснуллин җитәкләде. Форумга әзерлек тә федераль дәрәҗәдә барды. Март аенда М.Хөснуллин һәм Россия тышкы эшләр министры С.Лавров Мәскәүдә, аңа әзерлек максатында, Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең илчеләрен җыеп, хәтта махсус тәкъдим итү чарасын да үткәрде. Ә яңа статуслы «KazanForum 2023», чыннан да, зур әзерлек һәм киң колач белән үтте кебек. Анда дөньяның 85 иленнән, шулай ук Россиянең 84 төбәгеннән вәкилләр җыелган. Форумда 45 дипломатик миссия һәм 37 гадәттән тыш вә тулы вәкаләтле илче катнашкан. Ә иң зур делегацияләр Азәрбайҗан, Иран, Малайзия, Таҗикстан, Төркия, Үзбәкстаннан килгән. Россия хакимияте исә анда вице-премьерлар А.Белоусов, М.Хөснуллин, А.Оверчук дәрәҗәсендә күрсәтелгән, чарада шулай ук 17 субъект җитәкчесе һәм хәтта, кунак буларак, Мәскәү вә бөтен Россия патриархы Кирилл катнашкан.

«KazanForum 2023»нең пленар утырышына килгәндә, аның рәсми өлешен Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Коръәннең «Әл-Хәҗҗ» (Хаҗ) сүрәсеннән 73-78 нче аятьләрне укудан башлап җибәргән. Аеруча зур игътибарны анда Аллаһка гыйбадәт кылырга, туганлык җепләрен сакларга, күркәм әхлаклы булырга һәм игелек эшләргә чакырган юллар җәлеп итә. Ә Аллаһ өчен бар көчне сарыф итеп, Ул лаек булганча җиһад кылырга өндәгән 78 нче аять инде бүгенге катлаулы чорда бигрәк тә актуаль яңгырый. Пленар утырышта Форумга йомгак ясалган, шулай ук халыкара процессларны җайга салу вә тотрыклы глобаль үсеш балансына ирешү юлында Россия һәм Ислам хезмәттәшлеге илләренең үзара файдалы мөнәсәбәтләрен үстерү планнары һәм перспективалары билгеләнгән. Патриарх Кирилл исә мондый халәтне, «православие сегодня нашло себе опору в исламских странах», дип аңлаткан.

Ә татар дин әһелләренең «Милли тормыш һәм дин» дигән XIII Бөтенроссия форумы пленар утырышында әйтелгән фикерләренең актуальлеге ягыннан игътибарны бигрәк тә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның көнүзәк мәсьәләләрне яктырткан чыгышы, шулай ук Казанның «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге мәдрәсә җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншинның «Татар мәдрәсәләре – татарлык терәге» дигән темага доклады җәлеп итә. Әлбәттә, кызыклы фикерләр кайбер башка чыгышларда да яңгыраган.

Инде сәяси нәтиҗәләргә дә кыскача тукталыйк. Яңа статуслы «KazanForum 2023» үз алдына куйган максатларына ирешә кебек. Гомумән алганда, аны чиста геосәяси проект дип тә карарга була. Чөнки ул Россияне бүгенге кыен хәленнән чыгаруда төп диннәрне сәяси вә икътисади яктан кулланучы максат итә. Әмма аны оештыручылар, үзләре дә абайламастан, метасәяси (илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүне максат иткән) юнәлештә дә җитди адым ясадылар: Ислам дөньясы вәкилләре тәүге тапкыр Изге Болгарга – ислам яңарышы үзәгенә җыелды. Димәк, иртәме-соңмы, илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү хәрәкәте дә, Аллаһ ихтыяры вә кодрәте белән, Изге Болгардан һәм Урталык җирләреннән башланыр.

Фоат УРАЗАЙ.

Пәйгамбәребез ядкәрләре – Татарстанда

Үткән атнада Изге Болгар җыены кунаклары, Казан халкы Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлам һәм аның сәхабәләренең ядкәрләрен күрә алды. Кыйммәтле йөкне Татарстанга Дагстан мөфтие урынбасары Мөхәммәдрәсул хаҗи Саадуев җитәкчелегендәге Дагстан Республикасы делегациясе озата килде.

Болгарда тәкъдим ителгән күргәзмәдә Мөхәммәд Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең май касәсе һәм кылычы, сәхабә Билал радыйаллаһу ганһе, Пәйгамбәрнең хатыны Гайшә радыйаллаһу ганһә һәм кызы Фатыйма радыйаллаһу ганһәнең чүлмәкләре, кул тегермәне, Халид ибне әл-Вәлид радыйаллаһу ганһенең сәфәрләрдә йөртә торган фляжкасы һәм көбәсе, Әбү Бәкер әс-Сиддыйк радыйаллаһу ганһенең пычагы бар иде. Әйберләрне Татарстанга беренче тапкыр алып килделәр.

Тантаналы очрашуда Равил хәзрәт Зөфәров кунакларны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән сәламләде һәм экспозицияне оештырган өчен Дагыстан мөфтие Әхмәт хаҗи Абдуллаевка, ике республика җитәкчеләренә рәхмәт белдерде. Дагстан мөфтие урынбасары Мөхәммәдрәсул Саадуев Казанда ядкәрләргә зур хөрмәт күрсәтелгәнен билгеләп үтте. «Ядкәрләр безне исламның данлы тарихы белән бәйли. Бу ядкәрләрнең килүе Татарстан өчен иминлек, иман яңарышы билгесе булсын», – диде ул.

Мөфти урынбасары сүзләренчә, Дагстанда бу ядкәрләр мөфтинең шәхси җаваплылыгы белән, кояш нурлары төшми торган, тиешенчә шартлар тудырылган ябык бинада саклана. Татарстанга алар Дагстан осталары ясаган һәм бикләнә торган махсус сандыкларда килгән. Ул шулай ук гарәп гаиләләрендәге бу әйберләрнең буыннан-буынга гаиләдәге кадерле әйберләр итеп тапшырылганын сөйләде. Әлеге ядкәрләрне Изге Болгар җыеныннан соң Казан Кремле кунаклары да карый алды.

Э.СӘГЫЙДУЛЛА.

Олуг әдип сабагы

Дүшәмбе кичендә Г.Камал исемендәге татар академия театрында Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты Рабит ага Батулланың 85 яшьлегенә багышланган иҗат кичәсе узды. Ул һич кенә дә шау-шу яки уен-җыр кичәсе булып чыкмады, халык әдибе чыгышы ул кичтә җанында бер мыскал татарлыгы булган һәммә кеше өчен әдәбият сабагы, тарих сабагы булып яңгырады.

Кичә гаҗәеп, һич көтелмәгәнчә башланды-башлануын. Камал театрының дистәләгән артисты йөзләрнә Батулла сурәте ясалган битлек киеп чыгып, тамашачыны чиксез аптыратты. Чөнки Рабит агай үзе дә һич гади түгел, аны йөз төрле һөнәр иясе дип атасаң да була. Ул телевизор экраннары аша экиятче бабай булып та, заманында Тукай клубының дилбегәсен үз кулында тоткан сатирик, татар театрларының батыр режиссеры, «Сөенбикә» кебек романнары белән әдәбиятны шаулаткан тарихчы, хәтта Биектау районындагы үз йортында чыпчын авыл музее ачкан мирасханә сакчысы булып та, халык күңеленә барып керде. Ләкин ясалма битлек киеп кенә, Батулла биеклеген яулап булмый, шуңа шамакайларның күбесе тиз арада сәхнәдән юкка чыкты.

Ә Батулла агай безне әдәбият һәм тарих сабагы белән тәмам шаккатырды. 85 яшьтә дә бөек Кол Гали, Мәүлә Колый, бөек Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Һади Такташ, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Зөлфәтләрнең иң беренче һәм соңгы итеп язган шигырьләрен яттан тезеп сал әле! Һәм гади генә сөйләп чыгу да түгел бит, ә шул әсәрләр аша бөек шагыйрьләрнең һәлакәтен, ачы язмышын аңлатып бирә ал. Әйтик, Һади Такташның «Газраилләр» әсәрен ничә йөз кеше генә игътибар белән укып чыккан да, шуны гомерлеккә ятлап кала алган? Бактың исә, Такташның «Газраилләр»е бүген дә кадерле, 16 яшьлек егет кеше әле шул чагында ук урыс иленең барча шакшылыгын, ерткычлыгын һәм бәхетсезлеген ачып салган. Кан коюлар тиктомалдан гына дәвам итми, кеше җанын кыючы газраилләр һаман безнең сафта, алар исән икән...

Әдипнең Бөек ана теле белән туган милләтебезне саклап калу һәм аны хөр итү турында әйткән фикерләре дә бик кыйммәтле. Тату гаилә корып та, иманлы балалар үстереп тә була. Ләкин халкы азат булмый торып, бер генә каләм остасының да үзен тулысынча бәхетле санаенсы юк. Рабит ага безгә шуны аңлатып бирә алды. Шушы татарлыгын, аның туган халкына мәхәббәтен Татарстан Хөкүмәте Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев та, төрек-татар язучысы Фатих Кутлу һәм, әлбәттә инде, аксакалның ике газиз улы – Нурбәк белән Байбулат, безнең танылган җырчыларыбыз да чиксез хөрмәт итә.

И.ВАХИТОВ.

1 нче биттә – «Соңгы кыңгырау» бәйрәмендә чыгарылыш сыйныф укучылары. Фото Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының «Вконтакте» челтәрендәге рәсми төркеменнән алынды.

«Казан басмасы»н мәңгеләштерү

Беренче басма Коръән – «Казан басмасы» булып тарих сәхифәләренә кереп калды. Изге Китабыбыз 1803 елда Г.Бурашевның Азия басмаханәсендә басма рәвештә дөнья күрде. Быел бу олы вакыйгага 226 ел тулды. Коръән Екатерина II нең карары нигезендә басыла. Шрифтлар гарәп графикасы кагыйдәләре нигезендә татар дин әһелләре тарафыннан ясала.

Шушы көннәрдә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Казан федераль университет җитәкчелеге, галимнәр, укытучылар, студентлар, журналистлар катнашында тантаналы рәвештә университетның төп бинасы ишегалдында «Казан басмасы» чыгу вакыйгасын мәңгеләштергән истәлек тактасы ачылды. Бакырдан эшләнгән элмә тактада татар, рус һәм гарәп телләрендә, «Бирədə 1803 елда мөселманнар тарафыннан Г.Бурашевның Азия басмаханәсендә соңрак «Казан басмасы» буларак танылган Кәлям Шәриф бастырылды. Шул вакыттан Казан дөньяда Коръән күпләп бастырылган беренче шәһәргә әверелде», – дигән сүзләр язылган.

Тантананы Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин «Әл-Хәшер» сүрәсеннән аятьләр укып ачып җибәрде. Мөфти хәзрәтләре «Коръән Һиҗазда иңгән, Каһирәдә укылган, Истанбулда язылган, Казанда бастырылган» – дигән сүзләр белән Коръәнне бастыруның татар халкы һәм мөселман өммәте тарихындагы әһәмиятен тагын бер кабат искәртеп үтте. Рөстәм Нургали улы да үз чиратында бүгенге чараны тарихи мөһимлеген ассызыклады.

Тантанада катнашучыларны Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин һәм Россия мөселманнары Дини Мәҗлесе рәисе Әлбир хәзрәт Крганов, Россиянең Азия өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Нәфыйгулла хәзрәт Аширов сәламләде.

Коръән бастыру традициясе Казанда бүген дә дәвам итә. 2017 елда Татарстан мөселманнары Диния Нәзарәте әзерләгән Коръән басмасы халыкара стандартларга туры килә дип танылды, ул шуннан соң Үзбәкстан, Төркия һәм Белорусиядә дә дөньяга чыкты, ә 2022 елда Идел буе Болгар дәүләтендә ислам кабул ителүнең 1100 еллыгы кысаларында Нәзарәт «Казан басмасы» дип исемләнгән компьютер шрифтын эшләде һәм аның нигезендә яңартылган «Казан басмасын» әзерләп 10 мең тираж белән бастырылды, Изге китап бәйрәм тантаналарында катнашкан дин әһелләренә, зыялыларга, кунакларга таратылды.

Сөембикә КАШАПОВА.

Хөрмәтле артист иде

Питрәч районы Күн авылында Камал театры актеры, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Айдар Хафизовның кеберенә таш кую мәрасиме булды.

Тантанага Айдар Хафизовның хәләл җефете Фәридә ханым, Питрәч районы башлыгы Илһам Кашапов, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Равил Шәрәфиев, Айдар Хафизовның шәкерте Гүзәл Шакирова, Камал театры актерлары, мәрхүмнең кияү-кызлары, оныклары һәм авылдашлары җыелган иде.

Чараны Күн авылыннан Габдулла хәзрәт аять-сүрәләр уку белән башлап җибәрде.

«Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын», – диелә шигырьдә. Бу юллар Айдар Садри улына атап язылган шикелле. Хезмәтеңне, иҗатыңны халыкка багышласаң, үзең дә халык тарафыннан сөелерсең, мәхәббәтен казанырсың. Айдар абыйга рәхмәтебез чиксез, ул татар театрын, мәдәниятен, телен үстерүгә бәяләп бетергесез өлеш керткән шәхес. Инде ике ел рәттән үткәрелә торган театр атналыгы, мәктәптәге чаралар Айдар Хафизов истәлегенә багышлап үткәрелә», – диде И.Кашапов.

«Ул төрле пландагы рольләрне уйнады. «Арбалы хатыннар» спектаклендә аның роле зур да, уңай да түгел, әмма сәхнәдән кереп киткәндә аңа кул чаба иделәр. Аның табигыйлыгы, артист булганы өчен алкышлыйлар иде», – дип искә алды Равил Шәрәфиев.

Камилә БИЛАЛОВА.

«Туган Батыр» форумда тәкъдим ителде

Казанда XIV «Россия – Ислам дөньясы» Халыкара форумы кысаларында Казанда йөзләп чара үтте. Шулардан берсе: «Туган Батыр» исемле татар милли герое турындагы мультфильмны да тәкъдим иттеләр һәм тизер-трейлерын кунакларга күрсәттеләр. Фильмның беренче сериясен тамашачы 2024 елда карый алачак, һәр сезоны алтышар минутлык 52 сериядән торачак, дип хәбәр итте аны эшләүчеләр. «Безнең проект мәхәббәт турында. Җиргә, туган телгә, кешеләргә, Ватанга, мәңгелек кыйммәтләргә мәхәббәт», – дип сөйләде «Туган Батыр» проектын нигезләүче, «Туган авылым» туристлык комплексын оештыручыларның берсе Радик Абдрахманов.

З.Хәкимнең мультфильмга нигез итеп алынган әсәре әдәби конкурста балалар китабы номинациясендә инде җиңү дә яулаган. «Минемчә, әкиятләр һичшиксез кирәк. Алар гомеребез буена үзгәрмәс кыйммәтләрне җиткереп торалар, яхшыны начардан аерырга өйрәтәләр», – диде автор. Икенче китап каһарманның сәяхәтләре хакында, ә өченче китап бәхет турында булыр, дип ышандырды язучы.

Әлеге проектны эшләүчеләр 2026 елга кадәр Россия күләмендә танылырга, шулай ук Якын Көнчыгыш, Төркия, Төньяк Африка һ.б. илләргә чыгарга дигән максат куйган. Проектны Казахстанда һәм Төркиядә тәкъдим итү турында килешүләр инде төзелгән, китап төрек теленә тәрҗемә ителәчәк. Шулай ук проект биржага чыгарылачак һәм төрки-гарәп дөньясына карау мөмкинлеге ачылачак, дип хәбәр итте Абдрахманов. Туган Батыр татар милли образын балалар һәм яшьләр арасында таныту өчен, шул бренд белән төрле чаралар да үткәреләчәге хакында сөйләп үтте ул. Әйтик, бу юнәлештә компьютер уеннары, комикслар, сувенирлар эшләү күздә тотыла.

ILAR компаниясе директоры Илдар Низамиев әйтүенчә, 1,5 ай эчендә проект белән 5,5 млн кеше танышкан. «Туган Батыр – традицион кыйммәтләрне туплаган җыелма образ. Китаптан тыш, нейрочелтәр ярдәмендә образны күзаллап, тышкы кыяфәтен дә тудырдык, ягъни тышлык сурәте җанланды», – диде ул.

Эльмира СИРАҖИ.

«Хәләл» сүзе гаделлекне таләп итә

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» Халыкара икътисад форумының беренче көнендә Казан үзәгендә «Справедливый бизнес» юридик агентлыгы ачылды. Аны танылган мөселман адвокаты Руслан Нәгыев һәм «Ханский дом» төзелеш компаниясе башлыгы Ильяс Гыймадов җитәкчелегендә Юристларның Милли Ассоциациясе Россия законнары һәм ислам хокукы стандартлары нигезендә эшмәкәрләргә бизнес алып бару буенча ярдәм күрсәтү максатыннан оештырды. Аерым алганда, сүз гаделлек һәм әдәп-әхлак нормалары буенча килешүләр төзү һәм гамәлгә ашыру хакында бара.

Гамәлгә куючы билгеләп үткәнчә, бизнес-тирәлектә эшмәкәрлекне алып бару буенча юридик консультацияләр генә түгел, ә дини киңәшләр дә сорап килүчеләр бар. «Справедливый бизнес» офисы нәкъ менә шушы максатларны истә тотып эшләячәк: монда эшмәкәрләргә юристлар һәм шәригать белгечләре тарафыннан консультацияләр алу мөмкинлеге тудырылачак. Шул рәвешле, әлеге агентлык Татарстанда ислам инфраструктурасын үстерү өчен гамәлгә ашырыла торган «Halal life style» концепциясен киңәйтте.

Шул ук вакытта проект Россия Юристларының Милли Ассоциациясе һәм Татарстан мөфтияте өчен уртак булып тора: аны гамәлгә ашыру өчен мөфтият экспертлары – Нәзарәтнең шәригать мәсьәләләре буенча бүлек җитәкчесе, Голәмалар шурасы әгъзасы Булат хәзрәт Мөбарәков һәм Нәзарәтнең дәгъват бүлеге җитәкчесе Әхмәд хәзрәт Әбү Яхья җәлеп ителде.

Офисның рәсми ачылышында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты. Ул мөселман юристлары төркеменең ният-гамәленә хәер-фатихасын бирде һәм аларга, бөтен Россиягә үрнәк күрсәтеп, федераль киңлеккә чыгуларын теләде. Руслан Нәгыев шул ук вакытта агентлыкның мөселманнарга гына түгел, ә барлык теләүчеләргә дә хезмәт күрсәтәчәген билгеләп үтте: ул теләсә кайсы эшмәкәр өчен кызыклы булачак, чөнки бизнес алып баруның ислам стандартлары асылда әхлакый стандартлар булып тора.

– Элек кешеләр ислам хокукы буенча бизнес алып бару мәсьәләләре буенча консультацияләр алу өчен Диния нәзарәтенә мөрәҗәгать итте. Ә сату-алу килешүен Россия кануннары нигезендә башкару өчен юристларга баралар, соңыннан исә шушы ике килешүне берләштерергә туры килә иде. Бездә боларның барысы да бер урында булачак, – дип сөйләде Нәгыев.

Агентлыкның ачылу тантанасында Камил хәзрәт юристларга хәләл һәм аның чикләре төшенчәләренең нечкәлекләре турында вәгазь сөйләде, сораулар туганда тәҗрибәле белгечләргә мөрәҗәгать итүнең мөһимлеген ассызыклады.

Э.СӘГЫЙДУЛЛА.

● Халык саны буенча Һиндстан Кытайны 2,9 миллион кешегә узып киткән. Хәзер Һиндстанда 1,4286 миллиард, Кытайда 1,4257 миллиард кеше яши. Кытайда уртача гомер озынлыгы 82 (хатын-кызлар) һәм 76 (ир-атлар) елга, Һиндстанда исә 74 һәм 71 елга тәңгәл.

● Чит илләрдә эшләүче табибләр саны буенча да Һиндстан беренче урында: горбәттә хезмәт куючы барлыгы 74455 һинд табибе кире үз ватанына әйләнеп кайтса, илдәге медицина хезмәткәрләре штаты 7,3 процентка артыр иде. Пакьстан ватандашы булган 25607 медик, 21800 румын һәм 18827 немец табибе, Россия ватандашы булган 17227 (бу РФдәге югары белемле медикларның гомуми санының 3,1 процентын тәшкил итә) табиб тә чит илләрдә эшли.

● Федераль иминлек хезмәте ике Колумбия гражданы һәм бер Европа дәүләте ватандашын кулга алган. Алар Россия территориясенә Латин Америкасыннан 699 кг (күпләп сату бәясе – 2,5 миллиард сумлык, ваклап сату бәясе 6 миллиард сумлык) кокаин кертүдә гаепләнә. Кокаин Мәскәү янындагы складта табылган, соңрак аның бер өлешен Европага җибәрергә, бер өлешен исә Россиядә сатарга җыенганнар.

Казанда «Милли тормыш һәм дин» XIII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы узды. Ул быел «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2023» халыкара икътисад форумы кысасында үткәрелде. Аның эшендә катнашу өчен Россиянең 77 төбәгеннән һәм Татарстаннан 1000 нән артык дин әһеле – делегат килде.

Милләтебезне дин саклый

Җыенның пленар утырышының беренче өлеше Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашында «Казан Экспо» күргәзмә үзәгендә һәм икенче өлеше Татарстан Фәннәр Академиясендә үтте. Утырышны Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев ачып җибәрде һәм алып барды.

Халкыбызны Сабан туе, бәйрәмнәребез берләштерсә дә, Аллаһ Тәгалә тарафыннан сынау итеп җитбәрелгән афәтләр, кайгылар да бердәмлекне ныкыта, бер-беребезгә терәк булырга теләү хисләрен арттыра. 2021 елның 6 мае көнне Омск өлкәсендәге Каракүл авылы янып, аны торгызуга барча татар халкы ярдәм итсә, быелның май таңында татар халкын тетрәндергән тагын кайгылы хәбәр килде: Курган өлкәсенең Йолдыз (Эчкен) авылында янгын чыгып, 250 дән артык йорт көлгә әйләнде, 7 кеше һәлак булды. Бөтендөнья татар конгрессы, мөфтиятләр, тетрәндергеч хәбәрне алу белән, гуманитар ярдәм итү акциясен игълан итте. Тамчыдан күл җыела. «Ике көн эчендә 2 миллион акча җыелып, 20 тонна гуманитар йөк озатылды. 22 майда тагын өч фургоннан торган ярдәм кәрваны төбәккә юл алды», – диде В.Шәйхразыев. Милли Шура рәисе үзе дә Курган өлкәсенә барачагын, халык белән очрашачагын белдерде. Мәктәпләрдә укулар башланганчыга кадәр, Йолдыз авылы мәктәбендә яшәүчеләрне йортлы итү бурычы куела. «Безнең төп максат – авылны саклап калу, тиз арада янгын урыннарын чистартып, казага тарыган халык өчен йортларны күтәрә башлау. Йолдыз авылына «Татнефть» ширкәтенең хәйрия фонды да ярдәм кулы сузарга әзер икән, тиз сафка баса торган йортлар төзү турында карар кабул иткәннәр. Йолдыз авылын бергәләп торгызып, йортлар салып, бердәмлек урамнары булдырырга дигән тәкъдимнәр дә булган. «Шулай итеп Йолдыз авылы татар халкының бердәмлеге символына да әверелде», – диде В.Шәйхразыев.

Форумга Йолдыз авылының имамы Әхмәдулла хәзрәт Хәбибуллин да килгән иде. «Авылыбызның 1000 еллык тарихы янды. Бу – Аллаһ Тәгалә тарафыннан бирелгән сынау булуын беләбез. Без аны үтәрбез – дип ул авыл халкының үтенечен җиткерде. – Әмма Татарстан булышлыгыннан башка авылны күтәрергә авыр булыр, диләр. Эчкен халкы ярдәм көтә, – диде имам, Татарстан Рәисенә мөрәҗәгать итеп.

Россия Мөфтиләр Шурасы рәисе, Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти-шәех Равил хәзрәт Гайнетдин дә, Йолдыз (Эчкен) авылына ярдәм – бердәмлекнең бер күрсәткече булуын ассызыклап үтте, изгелек кылуда тукталмаска, шәфкатьле, мәрхәмәтле булырга кирәклеген искәртте. «Милләтебез Евразия кыйтгасы тарихында дипломат, эшлекле, мәгърифәтле халык буларак танылган. Без Исламны Японияләэн Скандинавиягә кадәр тараттык, мәчетләр төзедек. Әмма халкыбыз алдында тагын бер зур бурыч тора: остазларыбыз булган галим-голәмаларыбызның мирасын саклау һәм киләчәк буыннарга тапшыру. Безнең XVIII гасыр, XIX-XX гасыр башындагы галимнәребез дәрәҗәсенә җиткәнебез юк. Безнең максатыбыз галимнәрне тәрбияләү», – диде ул.

Россия мөселманнары Дини җыены рәисе, Мәскәү шәһәре, Үзәк төбәк һәм Чуашстан мөфтие Әлбир хәзрәт Крганов та халкыбызның авыр чакта бер-берсенә иңнәрен куя кебек асыл сыйфаты ачылып китүен искәртте. Нижневартовск эшмәкәрләре фаҗигане үз йөрәкләре аша үткәргән һәм Йолдыз авылындагы бер гаиләгә йорт салып бирергә килешкәннәр. Чуашстан мөселманнары да бер укытучы гаиләсен йортлы итү турындагы фикергә килгәннәр. Ә.Крганов шулай ук халкыбызның борынгыдан килгән дини һәм милли кыйммәтләрен дә бергә сакларга кирәклеген искәртте. Әлбир хәзрәт күтәргән актуаль мәсьәләләрнең тагын берсе – мәчетләребезне белемле дин әһелләре белән тәэмин итү. Дини уку йортларының күбесе Татарстанда урнашкан. «Әмма ислам югары уку йортларын тәмамлаган яшь татар белгечләребез Россиянең ерак төбәкләренә китәргә теләми. Нәтиҗәдә, Россиянең татарлар яшәгән шәһәр-авылларындагы күп мәчетләрдә имамнар җитми. Аллаһ йортларын яшь дин әһелләре белән тәэмин итү мәсьәләсе бик күптәннән хәл ителми тора», – дип, ул Урта Азия һәм Кавказ якларында яшь белгечләрнең, безнең якташларыбыздан аермалы буларак, социаль пакетсыз да эшләргә әзерлеген үрнәк итеп китерде.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин 2022 елның вакыйгаларга бай булуын искәртте һәм Мәскәүдә мәчет салу өчен урын бүлеп бирелү, Казанда, Уфада һәм Мәскәүдә иң эре мөселман уку йортлары өчен яңа корпуслар төзелү... Мөфти хәзрәтләре шулай ук дини әдәбиятны тикшерү өчен, Россиякүләм дини экспертлар оешмасы кирәклеген белдерде. «Зур тавыш чыгарган «Сахих әл Бохари»ның бер тәрҗемәсе тыелды. Шулай да мәсьәлә, белгәнегезчә, уңай хәл ителде. Ләкин шундый хәл тагын килеп чыкмас дип кем ышандыра ала? Россия мөселманнары бу вакыйгадан үзләре өчен дөрес нәтиҗәләр чыгарырга кирәк, ул, һичшиксез, безгә сабак булырга тиеш. «Мәсьәләнең асылында судларның гаделсез карарлары түгел, ә бәлки мөселман китапларына дини-фәнни анализ урынына психологик-лингвистик анализ ясалу. Китапларның текстларын «экстремистик» дип шуның нигезендә танныйлар. Ягъни Россиядә дини әдәбиятка экспертизаны тиешле әзерлеге булмаган белгечләр ясый. Югыйсә, басылып чыкканга кадәр, китап мөселман-дини экспертиза аша үтсә, күп сораулар үзеннән-үзе хәл ителер иде», – диде ул. Камил хәзрәт татар дини хезмәтләрне татар телендә язу һәм бастыру кулайрак икәнлеген дә, татарча язылган дини әдәбиятның тыелганы булмавын, шул рәвешле татарча китаплар базары үсеше өчен дә саллы өлеш кертеләчәген әйтте.

Россиянең Азия өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Нәфигулла хәзрәт Ашировны да борынгы бабаларыбыздан калган мирасны көндәлек тормышыбызда, балалар тәрбияләүдә, бер-беребез белән элемтәдә кулланмавыбыз борчый. «Ата-бабаларыбыз безнең алга Казан басмасын куйган кебек, без балаларыбызга нәрсә калдырабыз. Истәлек дип, чапан-чалмаларны калдырабызмы, яки Коръәннең мәгънәсен күңелләренә сеңдереп, калеб-йөрәкләренә кертеп, аларны да балаларын шул юлда тәрбияләргә өйрәтәбезме?» – дип чыгышын сорау белән тәмамлады Нәфигулла хәзрәт.

Оренбург өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти, «Хөсәения» мәдрәсәсе директоры Әлфир хәзрәт Шәрипов «Хөсәения» мәдрәсәсенең иске бинасы киләчәгә турында сөйләде. Татар автономиясе белән берлектә, бинаны кайтарып, анда татар милли-дини гимназиясен ачып, укытулар алып бару планлаштырыла. «Сер түгел: әби-бабаларыбыз динне һәм телне саклаганга күрә, милләтебез яши. Татарлар дини һәм рухи бай булганга иң укымышлы милләтләрнең берсе саналган. Мәдрәсәләр 1000 ел элек милләтебез данын күтәргән кебек, хәзер дә уку йортлары аша милләтебез телен, мәдәнияттен саклау кирәк, – диде Әлфир хәзрәт.

Казанның Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин да мәхәлләләрдә, мәчетләрдә, мәдрәсәләрдә милли рух – татар рухы булырга тиешлеген ассызыклады. «Милләт белән дин бергә булганда гына безнең киләчәгебезгә өмет итәргә мөмкин. Хәзер татарларга кирәкле милли мәгълүматны тулысынча җиткерә алучылар, безнең халыкның милли һәм дини йөзен билгели һәм саклый торган затлар – имамнар. «Безнең татар мәхәлләләре милләтебезнең яшәү рәвешен, төбәк тарихын, гореф-гадәтләре, туган телне, мәдәнияте, әдәбияты, халкыбызның сәнгатен өйрәнү, буыннан-буынга тапшырыла торган традицияләргә сакчыл карашны тәрбияләү үзәгенә әйләнергә тиеш. Имамга, авыл җирендә яки шәһәрдә нинди дә булса тарихи мәчеттә эшли икән, ул мәчет һәм авыл тарихын ныклап өйрәнү зарур», – диде ул.

Приморье краеның эчке сәясәт департаменты консультанты Юрий Колесниченко Владивосток тарихында беренче мәчетне Татарстан мөселманнары төзиячәген хәбәр итте. Бик авырлык белән генә мәчет өчен кулай урынны – Оборона министрлыгы карамагында булган җирне рәсмиләштергәннәр. Моның өчен Приморье крае губернаторы Олег Кожемяко һәм Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Россия оборона министры Сергей Шойгуга мөрәҗәгать иткән. «Төзелешне башлау өчен рөхсәт кәгазьләрен рәсмиләштереп бетерәсе калды. Төзеләчәк мәчет Татарстан мөселманнарыннан бүләк булачак», – диде Юрий Колесниченко.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов исламның кирәклеге һәм әһәмиятен дөрес булуын, динебезнең дөньядагы ямьсез күренешләргә каршы көрәшә алуын әйтте. «Дөньядагы хәлләрне беләбез, бозыклык, әхлаксызлык, традицион булмаган кыйммәтләр белән бергәләп көрәшергә кирәк. Алар белән ислам дине, православие көрәшә ала», – диде республика җитәкчесе. Р.Миңнеханов әйтүенчә, балаларыбызны, киләчәгебезне тәрбияләүдә, гореф-гадәтләрне сендерүдә татар дин әһелләренә зур ышаныч белдерелә. «Әгәр сезнең белән тыгыз элемтәдә бу эшне алып бармыйбыз икән, бу бер кешегә дә кирәк түгел. Әгәр татарның киләчәге булсын дип теләсәк, җыелырга, киңәшергә, мәдрәсәләр белән эшне оештырырга кирәк», – диде ул.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотосы.

Бу көннәрдә VIII «Мәрҗани укулары» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе үтте. Гыйльми җыен «Татарлар һәм ислам дөньясы» Бөтенроссия фәнни форумы кысаларында узды һәм күренекле татар мәгърифәтчесе, көнчыгыш белгече, тарихчы Хөсәен Фәезхановның туууына – 200 ел, аның остазы, атаклы дин галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең туууына 205 ел тулуга багышланды.

Үз фәнни мәктәбебез кирәк

Конференция Россия мөселманнары Диния нәзарәте, Мәскәү Ислам институты, Татарстан Рәисе администрациясе, ТР Фәннәр Академиясе, Казан федераль университеты белән берлектә оештырылган иде.

Конференциянең пленар утырышы Казанның Мәрҗани мәчетендә узды һәм «Хөсәен Фәезханов һәм Шиһабетдин Мәрҗани – бөек галимнәр, теологлар һәм мәгърифәтчеләр» дигән темага багышланды.

Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти шәех Равил Гайнетдин чыгышын узган елгы тантаналы вакыйгаларны искә төшерүдән башлады. Болгар дәүләтендә Ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үтүне, тантаналарда катнашу өчен 41 илдән делегацияләр килүен, хәтта Италиядән дә вәкилләр катнашуны ул татар халкы тарихын Россиягә һәм дөньяга таныту дип әйтте. Равил Гайнетдиннән гарәп илләрендә булганда, «Россиядә шулай тирән тарихлы мөселман халыклары яшиме-ни?» – дип тә кызыксынганнар. «Алар безнең турыда белми иде. Россия Президенты В.Путин белән берлектә динебезнең 1100 еллык юбилеен дөнья күләмендә үткәрү – Аллаһ Тәгаләнең рәхмәте», – дип билгеләп үтте хәзрәт. Ул шулай ук игътибарны мөселман белгечләрен әзерләү мәсьәләсенә юнәлтте. Безгә үзебезнең дини мәктәпләрдән үсеп чыккан кадрларны әзерләргә, бөек галимнәребез мирасына нигезләнгән фәнни мәктәп булдырырга кирәк. Бу уңайдан Хөсәен Фәизханов, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Ризаэтдин Фәхретдин, Исмәгыйль Гаспралы, Мөхлисә Бубый, Әбусуфьян Акаев һәм Миркасыйм Госманов исемнәре атап үтелде. «Хөсәен Фәезханов ярдәме белән үзебезнең дин белгечләренең мирасы илнең югары уку йортларында һәм фәнни үзәкләрендә өйрәнелә, үзебезнең мөселман теология мәктәбе торгызыла. Бу процесс 20 ел элек башланды. Россия мөселманнары, Россия өммәте дин әһелләрен әзерләү белән генә канәгатьләнә алмады. Безгә үзебезнең фәнни кадрлар, бөек галимнәребез мирасына нигезләнгән үз фәнни мәктәбебез, милләтебезгә Мәрҗани, Фәезханов кебек зур шәхесләр кирәк», – диде Равил хәзрәт Гайнетдин.

Ш.Мәрҗани белән Х.Фәезханов арасындагы мөнәсәбәтләр остаз белән укучы арасындагы рухи бәйләнеш мисалы. «Хөсәен хәзрәт үзенең Шиһабетдин хәзрәт белән очрашуын – тормышындагы Аллаһ Тәгаләнең мәрхәмәте икәнлеген аңлаган. Ш.Мәрҗани Сембер губернасыннан килгән, акыллы фикер йөрткән, сәләтле егетнең шәхес буларак формалашып җитүенә шаһит була. Иске Татар бистәсендә яшь Х.Фәезхановның таланты тагын да үсеш кичергән», – диде ул.

Татарстан мөфтие, ислам фәннәре докторы Камил Сәмигуллин искәртеп үткәнчә дә, Татар дини-илаһиятендәге казанышлар, аеруча Мәрҗани, Фәезханов һ.б. бөек татар дин галимнәре яшәп иҗат иткән XIX гасыр мирасы – татар халкы тарихында гына түгел, гомумән Россия өммәте тарихында да иң саллы өлеш. «Ул безнең тарафтан тирән аңлауны, тиешенчә бәяләүне һәм һәрьяклап анализлауны таләп итә. Юкка гына бу чор татар халкы тарихында Яңа заман дип исемләнеп йөрми», – ди ул.

XVIII гасыр ахырында Россия мөселманнарына дин тотуда чагыштырмача ирек бирелә. Дәүләт тарафыннан мөселманнарның мәдәни үсеше өчен беренче чаралар күрелмәсә дә, XIX гасырның ахырына татарлар үз тырышлыклары белән, дәүләт ярдәменнән башка, милләт ихтыяҗларыннан чыгып, көчле иҗтимагый институтлар булдырып өлгерә: мәктәпләр, мәдрәсәләр, мәчетләр, фондлар, китапханәләр, хәйрия оешмалары ача.

Россиядә ул вакыттагы социаль-сәяси шартлар бүгенге вәзгыятьтән күпкә кырысрак булса да, күп гасырлык көчләп чукындыру сәясәте алып барылуга да карамастан, халкыбыз шушы кыска вакыт эчендә бөек дин галимнәрен тәрбияли алган. Ә бүген Россия өммәте, дәүләттән сәяси һәм финанс ярдәме алып та, берничә дистә ел дәвам иткән атеизм чоры безнең рухи мирасны юкка чыгарды, дип һаман зарлана. Әлбәттә, ул юкка чыгарылмады, ә бәлки фондларда онытылып, тузан җыеп кына ята. Бүгенге заманның Россия мөселманнары аларны өйрәнү һәм тиешенчә бәяләү түгел, хәтта укый да алмый. Бу хезмәтләр бөтен дөнья халкына танытуга лаек булса да. «Ш.Мәрҗани Болгар һәм Казан тарихларын да өйрәнгән, хезмәтләрен калдырган. Аларны өйрәнеп, без бу шәхесләрнең никадәр милләткә гадел, тугры булып хезмәт итүләрен аңлыйбыз», – диде мөфти.

Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев Шиһабетдин Мәрҗанинең туууына 205 ел үтсә дә, аның хезмәтләре әлегәчә безнең якта тулысынча каралмаган, өйрәнелмәгән, халыкка аңлатылмаган икәнлеген искәртте. Милли Шура рәисе биш ел элек Шиһабетдин Мәрҗанигә 200 ел тулу уңаеннан Үзбәкстанга барып, халыкара конференцияләр үткәреп, элмә такталар куелуын, Казанда Мәрҗанигә һәйкәл ачылуын искә төшереп узды. «Форсаттан файдаланып калырга кирәк. Ш.Мәрҗани, Х.Фәезхановны мәңгеләштерү – милләтне дә мәңгеләштерү, дигән сүз. Хәзер исә Х.Фәезханов мирасына әйләнеп кайтырга форсат туды. Татар халкы һәм ислам дине – бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә. Татар халкы гасырлар дәвамында әби-балрыбыз кабул иткән ислам динендә тәрбияләнде. Бу безнең өчен үткәнебез һәм киләчәгебез», – диде ул.

В.Шәйхразыев мәгърифәтче-галим Каюм Насыйриның 200 еллыгына әзерләнә башлауларын да әйтте. «Аллаһка шөкер, татар халкыннан чыккан дин әһелләре, галимнәр бик күп. Хәзерге буынның төп бурычы – тарихны, шәхесләрне күтәрү. Яшьләрне тәрбияләп, мең елга алга – ислам диненә үрнәк булырдай татар дин әһелләрен әзерләргә кирәк». Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм фонды директоры урынбасары Дамир Хәйретдинов дин белгечләре, галимнәр Ш.Мәрҗани һәм Х.Фәезхановны киләчәк буыннарга мирас калдырган милләт каһарманнары, лидерлар буларак искә алырга кирәклеген белдерде.

XIX гасыр уртасында ук дөньяви һәм дини фәннәрне берләштерергә кирәклекне аңлау булган. Үз вакытында шәрык белгече, галим Мирза (Александр) Казембек мәдрәсәне тәмамлаган яшь егет – Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкерте – Х.Фәезхановны Санкт-Петербургка укырга чакыра. Х.Фәезханов Санкт-Петербургта академиклар, белгечләр белән аралашып, тирән белемле галим буларак җитешә.

«Ш.Мәрҗани белән Х.Фәезханов – дин, тарих, филология өлкәсендәге белгечләр. Ш.Мәрҗани Истанбул, Каһирә, Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләрендә Россия мөселманнарының күренекле, олуг шәхесе. Галим бу шәһәрләрдә госманлы һәм гарәп телләрендә аралашкан. Хөсәен Фәезханов исә бертигез дәрәҗәдә татар, казах, кыргыз каһарманы буларак кабул ителә. Ул төрле төрки халыкларның

тарихи мирасына үз өлешен керткән», – диде ул. Дамир Хәйретдинов Россиянең Көнчыгыш илләре һәм ислам дөньясы белән якынаюын искәртте.

Әлбәттә, фән алга бара, яңа кульъязмалар да табыла тора. Конференциядә Х.Фәезханов шәхесе һәм хезмәтләре аларны өйрәнү, милли рухи мирасын барлау мәсьәләсендә алып барылган эзләнүләр турында профессор, Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары, Мәскәү ислам университеты ректоры Дамир Мөхетдинов, Россия фәннәр академиясе профессоры Илья Зайцев, тарих фәннәре докторлары, профессорлар Айдар Хәбетдинов, Диләрә Госманова ясаган чыгышлар кызыксынып тыңланды. Камил хәзрәт Сәмигуллин искәрткәнчә, фондларда онытылган һәм тузан җыеп яткан кульъязмалар да, китаплар да әле шактый күп икән.

Конференциядә шулай ук «Наследие Хусаина Фаизханова» дигән сериядән Миркасыйм Госмановның «Заветная мечта Хусаина Фаизханова: повесть о жизни и деятельности» дигән фундаменталь хезмәте тәкъдим ителде.

Равил хәзрәт Гайнетдин Х.Фәезхановның 200 еллыгына махсус чыгарылган истәлек билгеләрен Милли Шура рәисе В.Шәйхразыев, «Мәрҗани» мәчете имам-хатыйбы Мансур хәзрәт Җәләлетдинов һәм Хөсәен Фәезханов мирасын өйрәнүдә үз өлешен керткән өчен тарих фәннәре докторы, КФУ профессоры, галим Миркасыйм Госмановның кызы – Диләрә Госмановага тапшырды.

Фәнни-гамәли конференция, пленар утырыштан соң, секция утырышларына бүленеп дәвам итте. Аерым алганда, галимнәр «Татар халкының мәгариф һәм педагогик фикерен үстерү тарихы», «Алтын Урда чорыннан соңгы төрки-татар дәүләтләренең тарихи һәм археологик тикшеренүләре», «Россиядә ислам теологиясе: бөек традицияләр, заманча тәҗрибә һәм үсеш юнәлешләре», «Россиядә ислам һәм көнчыгышны өйрәнү: яшь галимнәр һәм тикшеренүчеләр карашы» темаларына бүленеп эшләде. Конференциядә барлыгы 100дән артык чыгыш тыңланды.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары

Каш өстенә куеп кулын, туган як, Әнкәем күк, кайтыр юлым күзлидер...

(Танылган әдәбият тәнкыйтьчесе, шагыйрь һәм нәшир Мөдәррис Вәлиевнең тууына 70 ел)

ЯРЛЫКАВЫҢ ҖИТМИ

Кайгы-хәсрәт килсә, күкрәгемә
Җаның-тәнең белән сыенасың.
Икебезгә бүлгәч, бу авырлык
Азрак тия, диеп сөенәсең.

Яфрак очындагы чык шикелле
Энҗе алкаң дереләп китүен
Сизмимен шул һәм күрми дә торам
Гаҗиз булуыңны, әй газизем!

Бутыйм бугай кайчак хак, нахакны...
Ә син, кәефен кырдым, дип кызганасың.
Кызганырга мәҗбүр булуыңнан
Ояласың микән – кызарасың...

Бермәл күңел чишмәләрең куеруын,
Күзләреңдә сурәтемнең җуелуын
Сизмимен шул һәм аңламый торам
Хаклы булуыңны, йөз аклыгым!

Юлдан кайтсам – эзең бусагада,
Йөзләреңә моңсу сагыш кунган:
Көнләшүдән түгел, – борчылудан,
Зарыгып көтүдән, сагынудан.

Мена шулчак... сыймас булып кочагыма,
Мәхәббәтле дөнья ачыла сыман.
Сулган-корыган гөлләр яфрак яра
Күрешүче кулларыбыз җылысыннан.

Бер иңемдә – ялгызларның зарлы чагы.
Бер иңемдә – күңелләрнең парлы чагы!..
Тәүбәләрем тәмам кабул булсын өчен,
Җитми тора бары синең ярлыкавың.

АЙ КҮРГӘН – КОЯШ АЛГАН

Җиләкле алан... Соңгы чык
Эри чалгы йөзендә.
«Таңда килермен, көт! Таңда-а!.. –
Сагынуга син түз генә...»

Ак томан – ак чатыр шаһит:
Борылдым ярты юлдан! –
«Ул мәлдән китмәс идең шул,
Курыксаң югалтудан!»

Чал нарат шаһит – карт буйдак,
Ылысын коя аска:
«Көткән – сабыр, көтү авыр,
Юлыңны үлән басса...»

«Таңда килермен», – дип киттем.
Өнсез җыр – моңсу алан.
Үләндәге чыкларны да
Ай күргән – Кояш алган...

СУЛАР БОЛГАНГАН ЧАКТА...

Аккошлы күл тирбәлә дә,
Дулкын кага ярларга.
Упкыннарда йөргән уйлар
Кушыладыр аларга.

Күңел күлемдә аккошым,
Тидермәм җилен-карын, –
Сулар болганган чакта да
Ак калсын канатларың.

Калдырмасын сине язмыш
Яңгырларга-карларга, –
Ятлар ярын алкышларга,
Үзеңнекен – каргарга...

* * *

Сурәтеңне, ак болыттан пакь итеп,
Күзләремнең аязына яшердем;
Күкрәүләрең яңгыр булып таммады,
Тик аҗаган булдымыни яшенең?!

Сагынулар йөземә кабат чыкмасын, –
Аккан суга, искән җилгә саркылсын.
Кыл урталай бүлгән идек бәхетне...
Алып кил син үзеңдәге яртысын!

САРЫ ТӨНБОЕКЛАР

Сак бул! Сары яфрак аска тарта.
(Китап сүзе)

Сагынуымнан сары яфрак булдым, –
Күмеп китте ак кар.
Өзелгән яфраклар еламый да,
Яңадан кайтуны уйламый да
Өзелгән яфраклар.

...Күтәрелдем кайнар бозлар булып,
Салкын суга актым.
Дулкын кире какты сагышларны,
Әрнүләрне, хата-ялгышларны
Дулкын кире какты.

Әверелдем туган яктан килгән
Ялгыз бер болытка:
Сары төнбоеклар яуды кичен,
Тар бүлмәмнән киң дөньяга күчте
Сары төнбоеклар.

АК ЯУЛЫК

Әлки, Алпар, Муллавылы – юл башым,
Әнкәм фатихасы булды юлдашым.
Капка төбе, ап-ак яулык, моңсу йөз –
Юл башында кала, диләр, бетмәс эз.

Хәтер күзем еллар аша һаман да
Шул эзләрне армый-талмый эзлидер.
Каш өстенә куеп кулын, туган як,
Әнкәем күк, кайтыр юлым күзлидер.

АНА ХАТЫ

«Авыл дәфтәре»ннән

Шарт-шорт килеп яна, – ялкын
Ярсып ябырыла имән утынга.
Тәрәз капкачларын каерырдай булып,
Буран ярсый, котыра.

Күрше апа әйтеп хат яздыра:
Бер ашыгып тезә... бер тына.
«Уйлап йөргән сүзем күп иде дә,
Хат яздырган чакта онытыла!»

Ябык кулы – яулык почмагында,
Хәтер төенчеген аралый:
«Бүген төштә күрдем сине, кызым, –
Ак күлмәктән... көлеп карадың...»

Буран, арып, бусагага ята.
Утлы күмер мичтә аллана...
Бөтен дөнья тынып тора, ахры,
Хат яздырган чакта аналар...

Мөдәррис ВӘЛИЕВ

ЯЗМЫШ

Мин диңгездән киткән тамчы идем,
Диңгеземә кабат кайтыр идем,
Диңгеземә бер кайтасым килә!

«Кайтар!» – диеп мин ялвардым Җиргә,
«Кайтар!» – диеп мин инәлдем җилгә.

Дулкын канатында бер өн килде:
«Тамчы булсаң, кире кайтыр идең,
Үзең диңгез булгач – кайту юк».

БОЛЫН

Без яшьлектә бер җыр язган идек,
Көе калды сибелеп болынга;
Чишмә булып, күңелем болынында
Агыла шул көй, агыла тын гына.

Агыла да алып китә ерак, –
Гөлләр белән юлын бизәрмен...
Яшьлек чишмәсеннән алган көйнең
Онытмасак икән сүзләрен.

Язлар белән әйләним дә кайтыйм
Кайтавазлар булып, тын болын!
Сандугачлар эчкән чык сулары –
Бездән түгелеп калган моңдыр ул...

РОМАШКАЛАР

Көл өстендә –
Каска ярып үскән чәчәк –
Кайта – кайтмый чәчәге...
Ә без көттек:
Кайта,
 кайтмый,
 кайта...

Күпме ромашканың таҗын сүттек:
Кайта, кайтмый... –
Әтиләрне кайтарырга
 бер чук җитмәде.
Ромашкалар...
 каска белән капландылар,
Дәүләтләрне каска белән капладылар,
Кызган каска белән.
Аңамени – бар афәте бу дөньяның
 бар ялкыны?
Әмма афәт белми калкан-каскаларны.
Каска белми саклаганын
 кем башларын:
Батырлармы? Куркаклармы? –
 аңа барыбер!
Усаллармы? Юашлармы? –
 аңа барыбер!
Калкан-каска калган: тимер касә –
Тимер тавышы белән шыңшып,
Башлар түгел, ташлар ярылганда да
калган ул...

Хуҗасына тугрылыклы бер көчектәй,
Кабер өстендә ятып калган каска.
Аны тишеп,
 үчекләп, –
Кайта-кайтмый чәчәге... ак ташта...
Кайта-кайтмый...
 кайтмый...
 кайтмый...
әтиләрне кайтарырга бер чук җитми.

ДӘВАМ

(ветераннар сүзе)

...Әй, сез,
Безнең тездә үскән малайлар,
Шелтәлимсез безне кырыслыкта?
– Сынау бар:
 ир тормышта
 корыч – утта...
Без тормышның үзе кебек
 кырыс булдык:
Дөнья йөге авыр; иңгә куеп иңне,
Үткәрдек без чыктан-чыкка,
 чыктан-чыкка
Йөрәкләрдә кайнарлык һәм сафлык
 исән иде!
Әкрен кабынып, озак дөрли торган
 хисләр иде.
Артык шаулап яши белмәдек без,
Ялган бизәк безгә ят булды.
Гади булып,
 гадел булып кына
Без атладык еллар аркылы...
Әй, сез
 безнең тездә үскән малайлар,
Без казыган окопларда
 чирәм үскән,
Без күтәргән буралар да
 юктыр күптән...
Әмма бит сез – яңа буын, яңа заман –
Безнең дәвам!
Сез үзегез тормыш йөген тартасыз,
Сез үзегез хуҗа хәзер дөньяга.
Юллар озын; горур атлап үтегез! –
Корыч утта, ир тормышта сынала.

Татарстанның Аксубай районы җирлегендә урнашкан һәм кайчандыр республиканың иң зур 10 авылының берсе булган Яңа Ибрай (Чәтрән) халкыбызга күп кенә күренекле шәхесләр – дәүләт эшлеклеләре, хәрбиләр, галимнәр, әдәбият һәм сәнгать әһелләрен биргән. Алар арасында Әүлия Хәмид Чәтрәни, мәгърифәтче, язучы Галиәсгар Гафуров-Чыгътай, ТАССР Югары Совет Президиумы рәисе булып эшләгән Гали Динмөхәммәтов, философия фәннәре докторы, профессор, КФУда философиягә нигез салучы Мансур Абдрахманов, ТАССР һәм РСФСРның атказанган укытучысы, филология фәннәре кандидаты, күп санлы дәреслекләр, укытучылар өчен методик кулланмалар, программалар авторы Гөлчәчәк Әдһәмова, хәрби эшлекле, генерал-майор Алмас Әдһәмов һ.б. бар.

● Алмас Әдһәмовның уллары Сергей һәм Александр.

● Генерал Алмас Әдһәмов.

АЛМАС ӘДҺӘМОВ ҮРНӘГЕ

Әлбәттә, район, авыл күләмендә аларның һәркайсын хөрмәтләгән төрле кичәләр, тантаналар, бәйрәмнәр уздырылып тора. Шушы көннәрдә Яңа Ибрай авылында Бөек Ватан сугышы ветераны, хәрби эшлекле, генерал-майор Алмас Мәхмүт улы Әдһәмовның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы кичә узды. Аны оештыруда Яңа Ибрай урта мәктәбенең ветеран-укытучысы, мәктәп музеена нигез салучы, җирле ветераннар советы рәисе Шәүкәт Кәбиров һ.б. башлап йөрде.

Кунакларны – Алмас Әдһәмовның улларын, оныкларын, туганнарын һәм авылның төрле оешмаларда хезмәт куючы дәрәҗәле шәхесләрне – Мансур Абдрахманов исемендәге Яңа Ибрай урта мәктәбендә директор Ринат Мотыйгуллин җитәкчелегендә тантаналы төстә каршы алганнан соң, алар өчен мәктәпнең ике бүлмәсен биләгән Туган якны өйрәнү музеенда экскурсия башланды. Шәүкәт ага Кәбиров башлангычы белән оештырылган һәм аның тырышлыгы белән 33 ел дәвамында тупланган музейда авыл тарихы да, төрле вакыйгаларны хәтерләтә торган ядкәрләр дә, шушы якта туып үскән күренекле кешеләр турында сөйли торган стендлар да, аларның истәлекләре дә урын алган. Аннары кунаклар авыл зиратына юл алды. Биредә Алмас Әдһәмовның әтисе, озак еллар дәвамында авыл мәктәбендә балалар укыткан Мәхмүт Мотыйгулла улы Әдһәмов җирләнгән. Мәрасимдә катнашучылар, Мәхмүт Мотыйгулла улы рухына багышлап догалар кылганнан һәм кабергә чәчәкләр куйганнан соң, авылның үзәк паркына атлады. Биредә генерал-майор Алмас Әдһәмовның исеме алты ел элек бронза бюст куелып мәңгеләштерелгән. Аксубай район башлыгы Камил Гыйльманов җитәкчелегендәге делегация, кичә кунаклары һәйкәлгә чәчәкләр куйдылар.

Төп тантана Мәдәният йортында үтте. Ул Аксубай районы имам-мөхтәсибе, Татарстан Диния нәзарәте мөфтие урынбасары Равил хәзрәт Зөфәровның Алмас Мәхмүт улы рухына Коръән сүрәләре укып багышлавы белән ачылды. Район башлыгы К.Гыйльманов чыгышында А. Әдһәмовның, авыр вакытлар булуга карамастан, үз тырышлыгы белән белем алуын, Жуков белән очрашуын искә алды, аның чәтрәнлеләрнең генә түгел, районның, республиканың, илнең горурлыгы булуын искәртте. «Аксубайлыларга Ватанга тугрылыклы булу үрнәген китаплардан да, кинолардан да эзләргә кирәкми, А.Әдһәмовның тормышы һәм хәрби хезмәте һәркайсыбыз өчен өлге. Бүген яшьләребез арасында Әдһәмов кебек кешеләр күбрәк булса, неофашизмны тизрәк җиңгән булыр идек. Безгә Бөек Ватан сугышы елларындагы патриотизм җитеп бетми», – дип белдерде район башлыгы. Бүген Аксубай районыннан Украинада сугышта 12 ир-егет катнаша. «Алар үз бурычларын лаеклы үти. Дүртесен без инде югалттык», – диде К.Гыйльманов.

Яңа Ибрай авыл советы җитәкчесе Фәһим Кәбиров Яңа Ибрайда елдан-ел кешеләрнең кими, буш йортларның арта баруына борчылу да белдерде.

Туган якны өйрәнүче Ш.Кәбиров Чәтрән (авылның элеккеге исеме) сүзне еракттан – Әдһәмовларның борынгы бабалары Мотыйгулла хәзрәттән башлады. Чистай өязе Чаллы Баш авылында туып үскән егетне, мәдрәсә тәмамлагач, Яңа Ибрай авылына мулла итеп җибәрәләр.Ул авылның икенче мәхәлләсе мәчетендә гомеренең соңгы көннәренә кадәр (1909) имамлык итә.

Шушы авылда ул муллалар нәселеннән булган Гөзелниса белән гаилә кора. Бу никахтан Мәхмүт, Мирзазаһит, Йосыф исемле уллары дөньяга килә. Мәхмүт Әдһәмов башлангыч белемне авылда ала һәм алга таба укуын Чистайда «Камалия» мәдрәсәсендә дәвам итә. Егет 1907 елда туган авылына укытучы булып кайта һәм 45 елдан артык гомерен балалар укытуга багышлый. Мәхмүт аганың хезмәтләре «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены һәм күп кенә медальләр белән бәяләнгән.

Алмас Әдһәмов әтисе Мәхмүтнең икенче никахыннан туган бала була. Әмма бәләкәй Алмаска ана назы бик аз эләгә, малайның әнисе Нәсимә ханым авырып китә. Укытучы хезмәтендә булган Мәхмүткә авыру тәрбияләү мөмкин булмый. Нәсимә ханымны Мамадыш ягындагы туганнары тәрбияләп соңгы юлга озаткан. Әнисе улы Алмас хәтерендә томанлы хатирәләр белән генә сакланган.

Кечкенә Алмасның балачагы Чәтрәндә уза. Ул балачактан күңеленә нык уелып калган туган авылы мизгелләрен, матур табигатен – елга-күлләрен, урман-болыннарын, кизләү-коеларын, үзенең дуслары белән бергәләп су керүләрен, балык тотуларны, балачак уеннарын гомер буе татлы мизгелләр итеп хәтерендә саклый, яхташлары белән күрешкәндә искә ала торган була.

Алмас туган авылы башлангыч мәктәбендә дүрт сыйныфны тәмамлый.

Ул елларда укытучыларны төрле мәктәпләргә күчереп йөртәләр. Мәхмүт Әдһәмовка да Беренче Май районының Кармыш, Лашман, Шөгер районының Сугышлы, Тельман районының Колбай-Мораса, Яңа Чишмә районының Татар Волчые авыл мәктәпләрендә мөдир һәм директор булып эшләргә туры килә. Ә гаиләсе аның белән күчеп йөри. Алмасның Аксубайдагы рус мәктәбендә сигез сыйныфны алты елда укып тәмамлавы да аның тырышлыгы турында сөйли.

А.Әдһәмов гаиләнең педагоглык династиясен дәвам итү нияте белән Чистай педагогика рабфагына укырга керә. Аның көндез укып, кичен дәресләрдән соң һәм каникул вакытларында аз гына булса да акча табу нияте белән пристаньдә эшләгән чаклары да була. Аннары егет белем алуын Свердловскидагы Урал индустрия институтында дәвам итә. Сугыш алды елларында ни сәбәпледер югары уку йортларында стипендия бирү туктатыла. Ә Алмаска, ничек булса да, белем һәм һөнәр алу кирәк. Ул курсантлары дәүләт тәэминатында булган хәрби училищега укырга керергә карар кыла һәм теләгенә дә ирешә. 1941 елда А. Әдһәмов – Свердловск җәяүле гаскәрләр училищесы курсанты. Әмма сугыш язмышларга үз төзәтмәсен кертә, Алмас укыган курс училищены тизләтелгән программа белән 1941 елның августында ашыгыч рәвештә тәмамлый. Яшь лейтенант – пехотачы Әдһәмовны яңа формалашкан 357 нче укчылар дивизиясенә билгелиләр. Бу – сугышның иң кызган чаклары. Фашистлар барлык көчләрен Мәскәүне алуга юнәлтә.

Алмас 1941 елның декаберендә сугышка керә һәм Калинин шәһәре янында беренче чирканчыкны ала, аннары Калинин фронты составында Ржев, Сычев өчен канкойгыч сугышларда катнаша. Алмас Әдһәмов алга таба взвод командиры, пулемет ротасы командиры урынбасары вазыйфаларында сугыша. 1942 елның февралендә яшь офицер беренче тапкыр яралана. Бу авыр сугышларның берсендә – Ржев өчен барган бәрелешләрдә була. Аны гадәттә тәмуг белән тиңлиләр. Фашистлар яхшы коралланган, бу елларда совет сугышчыларының кулларында, гадәттә, винтовка гына. Кул сугышларына барып җиткән чаклар да була. Ә А. Әдһәмовның кулында – пистолет кына. 1942 елның гыйнварында шушы



● Кичәне оештыруда башлап йөргән Шәүкәт Кәбиров.

● Авылның Үзәк паркында истәлек фотосы. Алгы рәттә уртада – район башлыгы Камил Гыйльманов.

пистолетын тоткан килеш өч немец белән очраша һәм яралана. Вакыйга болайрак була. Дошманның разведчиклары елганың теге ягыннан бара. Ә егет суның бу ягында. Алмас аларга төзи, күпме пуля бар, барысын да атам, башка юл юк, дип уйлый ул. Генерал-майор соңрак: «1941-1942 елллардагы сугыш – ул тоташ күз яшьләреннән, каннан торды», – дип әйтә торган була. 1943 елдан гына совет гаскәрләрендә корал яхшыра, самолетлар пәйдә була, яу кырына танклар килеп керә.

Өч ай госпитальдә дәваланганнан соң, А.Әдһәмов кабат Калинин фронтына әйләнеп кайта. Ул 1944 елдан Балтыйк буе фронты составында дошманга каршы көрәшә, тагын берничә тапкыр яралана. Алмас Әдһәмов сугышны капитан дәрәҗәсендә тәмамлый, батырлыклары өчен орден һәм медальләр белән бүләкләнә.

1945 елның 24 июнендә Мәскәүнең Кызыл Мәйданында Бөек Ватан сугышында Җиңү хөрмәтенә Парад уздырыла. Анда Алмас Әдһәмов та җиңүчеләр сафында атлый. Ә 1985 елда Җиңүнең 40 еллыгы, 2000 елда 55 еллыгы уңаеннан уздырылган парадларда да ул сугыш ветераннары колоннасы башында бара. Җиңүнең 50 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә АКШта җиңүче союздаш илләр ветераннары белән очрашуда катнаша.

Алмас Мәхмүт улы Җиңү көнен каршылагач та хәрби хезмәтен дәвам итә. Ул 1948-1955 елларда М.Фрунзе исемендәге Хәрби Академиягә укырга керә һәм бер үк вакытта Мәскәү өлкәсе Солнечногорск шәһәрендә «Выстрел» курсларында укыта. СССРның югары чиндагы хәрбиләре катнашында үткәрелгән киңәшмәләрнең берсендә Оборона Министры, маршал Г.Жуковка «Сугыш коралларының яңа төрләре» турында доклад ясый. Академияне тәмамлаганнан соң, Мәскәү хәрби округында, 1961 елдан 1966 елга кадәр Германия Демократик Республикасында мотоукчылар полкы командиры дәрәҗәсендә совет гаскәрләре төркемендә хезмәт итә. Бу елларда ул алман телен дә әйбәт өйрәнгән була.

1971-1973 елларда А.Әдһәмов – Оборона министрлыгының «Военный вестник» журналының баш редакторы; басманың 50 еллык юбилеен билгеләп үткәндә, журнал РСФСР Югары Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнә.

1973-1987 елларда Алмас Мәхмүт улы СССР оборона министрлыгының Баш инспекциясендә өлкән инспектор булып хезмәт итә. 1978 елда А.Әдһәмовка генерал-майор дәрәҗәсе бирелә. Бу чорда аңа, тәҗрибәле хәрби инспектор буларак, округларда булып, хәрби көчләрнең барлык төрләре һәм техникалары буенча да эш итәргә туры килә. Ул бу хезмәтендә кадрлар белән эшләүгә аеруча әһәмият бирә. Үзенә һәм башкаларга карата таләпчәнлеге эшендәге иң кирәкле сыйфат була.

А.Әдһәмовның гомуми хәрби стажы 48 ел тәшкил итә. Ул Кызыл Байрак, 1 дәрәҗә Ватан сугышы, 2 Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары һәм күпсанлы медальләр белән бүләкләнә.

А. Әдһәмов, отставкага киткәннән соң да, Ватанга хезмәтен дәвам итә. Ул озак еллар Мәскәүнең Олимпия авылы районы Ветераннар Советы әгъзасы, Мәскәү шәһәренең Татарлар җәмгыятендә иң актив милләттәшләребезнең берсе була. Аның Татарстанның Мәскәүдәге вәкиллегендә дә һәрвакыт көтелгән кунак булуын әйтәләр.

Алмас Әдһәмов җәмәгате белән ике ул – Сергей һәм Александр исемле егетләр тәрбияләп үстерә. Алар әтиләрнең эшен дәвам итә. Бүген аларның берсе – полковник, икенчесе – подполковник дәрәҗәсендәге хәрбиләр. Сергей Әдһәмов күңелендә әтисенең иң матур тәэсирләр калдыруы турында сөйләде. «Ул үз тырышлыгы белән күтәрелгән кеше, хәрби училищега кергән, сугышларда үлем белән күзгә-күз очрашкан. Әти барлык авырлыкларны җиңеп барып, туган иле, ватаны өчен озак еллар хезмәт куйды, һәм иң мөһиме – гомере буе үз халкына тугрылыгын саклады. Ул шулай ук үзенең якыннарына, балаларына, туган ягына, иленә һәрвакыт ярдәмле булды. Ул зур сабырлыкка ия һәм бик зирәк акыллы кеше иде. Тормышта төрле хәлләр, уңышсызлыклар була. Ул андый хәлләрдән дә зур сабырлык белән бик акыллы белән чыга иде. Әти һәркайсыбызны яратты һәм безне бик саклады. Ул безнең укуыбызга да, тәртибебезгә дә зур игътибар бирде. Аның яшәү рәвеше, яңалыкка омтылышы – безгә үрнәк булды», – дип сөйләде ул. Алмас ага 100 яшенә якынлашып килгәндә дә, соңгы көннәренә кадәр заман белән бергә атларга, интернет белән дуслашырга, һәр яңалыкка игътибарлы булырга тырыша.

Туганыннан туганы, Финанслар министрлыгы белгече Роза Әдһәмова да Алмас абыйсын әтисе урынына калган кеше, дип атады. «Ул бик туган җанлы булды, әтине – Насыйх абыйсын, әни Мөнҗияне бик ярата иде. Мәскәүгә баргалап тордык. Безне һәрвакыт бик яхшы каршы алдылар, үзләре каядыр киткәндә, квартираны безгә калдыра иделәр», – диде ул.

А.Әдһәмовның Түбән Камада яшәүче дүртенче буын туганы Рифкать Хәйруллин аның 1970 нче елларда көзге пычрак көндә хәрби вертолет белән зират янына кайтып төшүен бүген дә күңелле бер вакыйга итеп хәтерендә саклый. Бөтен

● Султан уңга: РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча идарә җитәкчесе, полковник Рафаэль Мотыйгуллин, Яңа Ибрай авыл советы җитәкчесе Фәһим Кәбиров, Яңа Ибрай урта мәктәбе директоры Ринат Мотыйгуллин.

бала-чага өчен бәйрәмгә тиң вакыйга була ул. Генерал әтисе, туганнарының хәлләрен белеп, бергәләп чәй эчкәч, тагын очып китә. Алмас Мәхмүт улы хәрби инспектор булган чагында, Казанга, Идел буе хәрби округына, Оренбургка юлы төшкәндә, берничә тапкыр шулай вертолетта кайткан.

Яшьрәк чагында генерал Казанга, Чистайга, Аксубайга, Чәтрәнгә еш кайта торган була. «Әтисе Мәхмүт аганың 75, 80, 90 яшьлек юбилейларын зурлап үткәрде. Яңа Ибрай мәктәбенең 100 еллыгы, Мансур Абдрахмановның тууына 90 ел тулу тантаналарында рәсми кунак буларак катнашты», – дип искә ала Шәүкәт ага Кәбиров. А.Әдһәмов шулай ук Яңа Ибрай мәктәбенә, мәчетләренә дә матди ярдәм күрсәтә, гаеt көннәрендә авылда корбаннар чалдыра.

Яңа Ибрай авылы, район җитәкчеләре үзләре дә дәрәҗәле якташларын онытмый, Ш.Кәбиров 2-3 ел элек, дәрәҗәле авылдашына багышлап, «Безнең генерал» дигән затлы китап та язып чыгарган, аны Мәскәүгә барып генералның үз кулына тапшырып та кайткан.

Генерал-майор Алмас Әдһәмов 2021 елның ноябрендә вафат була. Ул Мәскәүнең Троекуров зиратында җирләнгән.

Яңа Ибрайда туып-үскән кешеләр арасында, кайда гына эшләсәләр дә, Алмас Әдһәмов үрнәгендә, авылын ташламаган, якташларына ярдәм итеп яшәгән кешеләр бар. РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча идарә җитәкчесе, полковник Рафаэль Мотыйгуллин, Россиянең атказанган энергетигы Сәгыйть Вәлиуллин – шундыйлардан. Авылдашлары бәйрәмнәр үткәргәндә дә, танылган авылдашларына багышлап китаплар чыгарганда да, нәкъ менә шундый якташларына таяна. Алар Алмас Әдһәмовка багышланган тантанага да кайтты, чыгыш ясады. Кичәдә шулай ук Россия оборона министрлыгы инспекторы, генерал-майор Анатолий Молостов, Аксубай һәм Чирмешән районнары хәрби комиссары Сергей Иванов, РФ Эчке эшләр министрлыгының Аксубай районы бүлеге ветераннар советы рәисе, майор Шамил Сәхәбетдинов һ.б. катнашты.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Мәдәни җомга
26 май
№20, 2023

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ

МОСТАФА

Халисә иренең уң йодрыгы сулыннан шактый зур икәнен бала тудыру йортыннан бәбиен алып чыкканда күрде. Мостафасы ап-ак чүпрәкләргә ыспай итеп төрелгән, өч төштән зәңгәр ефәк тасма белән аркылы бәйләнгән курчак-бәбине сул беләгенә сузып алгач, уң кулы буш калды. Бала – нәкъ әткәсенең беләге буйлы икән. Ә буш калган уң кулының йодрыгы – нигәдер нык итеп йомарлаган иде аны Мостафа – авыр балчык кушылып каткан туң таш, күзгә каткак булып, Халисәнең күз алдында калды.

Хатынның каушаган күзе, йодрыктан күчеп, иренең чыраена карады һәм имәнеп китте: иренең уң борын тишегә дә түгәрәкләнеп киткән тирән вә караңгы чокыр сыман икән ләбаса. Әрсез әрлән тишеге диярсең! Сулы килешле генә, кешечә!

Шундый гаҗәеп ачышлар да булыр икән, өч елдан артык бергә яшәп иренә җентекләп караганы да булмагандыр шул Халисәнең, татар баласы шул, мөселман кызы, кыюсыз, басынкы, юаш. Күрше авылдан бәбәй алып кайтып мәшәләнгән арада ирен алыштырып куймаганнар инде, үзгәреш Халисәнең үзендәдер, бәбәй тапканчы бер төсле иде ул, ана булгач, иренә тупырдап торган малай алып кайтып биргәч, Халисәгә дә күз ныклыгы ирешкәндер.

Авыр тапты бәбәен Халисә, Мостафасы аның тулгагы башлануын ишетеп кырдан, Кырынды өстеннән атын җан-фәрманга чыбыркылап кайтып керде. Сәке тирәсендә, чаршау артында орчык булып бөтерелгән Бәдриҗамал карчыкны өреп җибәрде, кара янып, ыңгырашып ята-ята мендәр-ястыкларын әчмәкләндерепбетергән хатынын юрганы белән сәкедән умырып алды, ә дигәнче хуш исле печән мул түшәлгән кабык арбага чыгарып салды. Үзе арбага утырмады Мостафа, үрәчәгә ябышып, дилбегә очын болгый-болгый атны куды. Юл буе хатынына сүз катмады, барып җиткәч тә: «Хәлең ничек?», дип сорамады. Хәер, больницалы Ишморза авылы өч чакрымда гына иде.

Гомер-гомергә шулай булды: сүзгә һәвәс түгел иде аның Мостафасы. Өйләнешүләре дә сүзсез диярлек узды. Сабан туе кичендә Халисә артыннан Ишморзадан килгән ике егет кайтты. Югары очны Түбәненнән аерып аккан инеш күперенә җиткәндә аларны лап-лоп басып Мостафа куып җитте. Куып җитүе булды, Халисәнең ике ягыннан голдыр-голдыр кайткан ике күркә йон булып юкка чыкты. Әле бер сүз әйтмәгән дә иде Мостафа! Шунда, күпер чыккач, еллар бөккән кәкре өянкегә кызның җилкәсен терәп, курач иңенә потлы кулын салып, Мостафа ике генә сүз әйтте: «Миңа чыгасыңмы?»

Кичке уеннардан кайтканда, кыз үз өзләренә басып кемнеңдер сагалап йөргәнен чамалый иде. Арттагы аяк тавышларын ишетеп тукталган мәлләре дә булды, туктала да иреннәрен учына ялгап, рәхәтләнеп көлеп тә җибәрә иде. Кайтучының кемлеге күптән сер түгел иде кызга, рәхмәт Ишморза егетләренә, әгәр бүген Халисәгә ияреп, Мостафаның кытыгын китермәсәләр, сүрән телле егет аны җылы өянкегә терәгән булыр идеме икән?

Халисә авыр куллардан да мәхәббәт акканын тоеп иркәләнсә дә, әдәп өчен генә карышып маташты, егет кулларыннан ычкынырга тырышып тартылды, теленнән йоп-йомшак сүз чыкты. «Бәй, әз-мәз сөйләшик әле, Мостафа абый», – диде. «Нием сөйләшәсең тагын?» – диде егет кызны кайнар кочагына сытып. Егетнең көче, уңганлыгы авылда мәгълүм, шуның өстенә Мостафа яхшы ата, тырыш ана баласы, Халисәнең сөенечтән ерылган авызын әле ярый Мостафа күрмәде, «риза» дигән сүзен генә ишетте.

Бригадир Хәнәфи, чуан зәхмәтеннән кыска муены күкле-зәңгәрле сыза -кутырлар белән мул бизәлгән, күзеннән өзлексез яшь агып торган карсак ир уртасы кеше, көзлектә, елга аръягындагы уңдырышлы акланда киндер басысы йолкыганда, Халисәнең артыннан мыштым гына килеп чыкты да нәзек биленнән эләктерде, сул имиен уа ук башлады. Мыш-мыш килә, тез башлары дерелди Хәнәфинең. Халисә рәхәтләнеп көлә башлагач, Хәнәфи куркынып артка тайчынды һәм: «Шайтан кытыклыймы әллә сине?» – дип сорады. «Шуңа көләм, – диде тыела алмыйча Халисә, – юка баш, кыеш манараңа дим, манараңа, сантый, Мостафаның уң йодрыгы төшсә, чүлмәк ватыкларыңны җыя алмыйсың инде җыюын. Шуннан көләм, буш чүлмәк!»

Күз будыларымыни, күз ачып йомганчы юк булды әрсез Хәнәфи, авырсы ис һәм соры төтен тузгытып, биек-биек киндер шүрелләре генә тирбәлеп калды.

Бәбәйне авылга-йортка алып кайткан-да, Мостафаның сөенечтән кысылган күзләренә дә, үрәчәдән салынып төшкән бүрәнә-бүрәнә ботларына да карый алмады, карамады хатын, карашын иренең саллы йодрыгыннан, уң кулыннан аера алмады. Койрыгын армиягә әзерләгән комсомоллар кискән «Корыч» исемле алаша сак кына теркелди, арбада бәбәй кайтканын сизгер ат чамалый, дилбегәне каерып диярлек тоткан Мостафа чөмгереп ала, ике йодрыгы да дилбегәгә уралып дәү ташбака сыман тез күмәчләрендә ята иренең, хатынның күзе нишләптер гел шул якка каерыла. Карый да куе керфекләре дерелди, нидәндер шигәйгән сыман нарасыена тартыла.

Бәбәй тууын җылы өметләр белән көтте Халисә, бала белән ешрак сөйләшмәсме ичмасам дип, сөеп-яратып иренә текәлде. Сүзчән түгел иде шул аның ире. Ишетә Халисә, күреп яши, яшьтәш-кордашлары килен булып төштеләр дә, дөрес – биана-биата тирәсендә бик тугарылып китмәсәләр дә – ирләре белән сөйләшеп-серләшеп туймыйлар. Чатан Гыйльметдинне генә күр! Бер пужум аша гына яшиләр, мунча кереп чыгып, ындыр артларыннан, инеш ярыннан өйләренә кайтып җиткәнче тәтә-тәтә өзмәс лыкылдыйлар. Бер-беренең алларына төшеп, узышаузыша дөнья хәтле тәмле сүзләр чәчәләр. Ызаннарында бәрәңге түгел, ничек сүз үсми икән аларның?

Ходавәндәм, Гыйльметдиннең кая барганы, ни күргәне бар дөнья йөзендә? Бар да сиңа, абзар артыннан ары киткәне юк тел бистәсенең. Укуы да өчле-тугызлы булды, җиде яшенә кадәр ыштан тәтемәде бичарага, күтен ялтыратып йөрде, көмешен ата каз чукыгач кына ерак бабалары киндер ыштан тегеп кигертте. Аягына кияр киеме булмады, беренче сыйныфта өйдән мәктәпкәчә яланаяк элдерә торган иде. Ә аның Мостафасы!.. Ашлы-сулы йортта, тәрбиядә үскәнгә гөрнәдир! Колчакка каршы сугышып йөргән. Малай гына булса да, дошман пулясы аямаган аны, ике тапкыр раненый булган, әллә ни хәтле ят авылларны күргән, калаларны узган, лазаретта яткан. Лазарет дигәнең эләкмәсә, тәмәкегә дә ияләнәсе түгел икән, шунда урыс солдатлары тирәсендә тартырга гадәтләнгән. Дөрес, өйдә пыскытмый, бәбәй тугач, ә элеккечә өйалдында гына тукталып калмый, суыкта-җилдә дә аулакка, мунча артына ук чыга.

Авылда бик якын күргән бик якын кешесе бар иренең – урам тәрәзәләре капма-каршы торган йорт хуҗасы Мидхәт. Көнләшеп куйган чаклары да бар Халисәнең, юк вакытын бар итеп, Мостафасы Мидхәтләргә кереп утыра. Авылга җәйге җылылар иңгәч, алар еш-еш очраша. Халисәләр капкасы алдындагы тәбәнәк эскәмиягә чыгып оялыйлар, гәпләшәләр, тәмәке пыскыталар. Сөйләшсәләр, Мидхәтнең сүзе бетми, телгә беткән нәмәрсә, сөйли-сөйли дә, ерык авыз, урам тутырып көлеп тә җибәрә. Башын яхшы ат сыман чайкый-чайкый, тыела алмыйча көлә инде ярык барабан! Һич шунда ишеткән кызыкларның берәвесен генә хатынына кайтып сөйләмәи икән Мостафа?!

Малайга бабасы исемен яратып Сөләйман дип ат куштылар. Улына да әллә ни сүзе юк Мостафаның, кайта, кул очына күтәреп үчти-үчти итә дә баш түбәсен пәп итә. «Сөйләш бала белән! – дип инәлә Халисә. – Син сөйләшмәгәч, аңа телне кем өйрәтер?» «Син», – ди гади генә итеп ире, көлемсерәп.

Дөньялар үзгәрә башлады, Мостафа белән Мидхәтнең бер-берсеннән ерагаер көннәре килде. Беркөн Мостафа комсомолга кереп кайтты. Әткә-әнкәсе рәнҗеде, Халисә гаҗәпләнде, Сөләйман атлы куш түбәле малай елады. «Колчакка каршы көрәшеп йөргән актив кызыл әрмис комсомолда булырга тиеш!» – дип үгетләгәннәр Мостафаны. Икенче көнне, кичен Мостафа гәләфи чалбар кигән, тыгыз буылган бил каешына алтатар элдергән бер егет иярдеп кайтты. Егет райуннан килгән икән, тумышы да бу якныкы түгел, теле дә мәзәк, «з» урынына «д» дип җибәрә. Халисә кече якка керде, авызын яулык почмагы белән каплап рәхәтләнеп бер көлде әле. Ничәнче сыйныфтадыр аларга яңа колхоз рәисенең кызын тагып җибәрделәр. Аның да «з»сы «д» булып чыкты. Әй көлгәннәр иде шул баладан Халисәләр! «Беднең бодау кыдыл бодау, үде кыдыл, үде дур!» Әллә кая китте рәис, белми дә калдылар. Әйбәт иде кызы, сылу иде, Халисә аннан күрмәкчә толым үстереп җибәрде.

Тыйнак, басынкы, ипле, берәүнең дә юлына аркылы тәпиләмәгән Мостафаның өзми-ташламый комсомол җыелышларына йөрүе авыл арасында фаш булгач, берәү дә башта ышанмады, һәммәсе раслангач, бот чабып көлделәр, кул сугып бәхәсләштеләр. Мидхәт бик сирәк, бәйрәм-сәйрәмнәрдә генә кергәли башлады. Вакыты да җитенкерәмәгәндер, бала басты аларны, хатыны юмарт вә бәрәкәтле коега тап булды, ел саен йә малай, йә кыз алып кайтты. Балага батса да зарланмады Җәмилә, ирен алак-шалак йөртмәде, өй мәшәкатьләрен бергә күтәрделәр. Мостафа сакал сәлперәйтеп комсамулда утыра, Халисә койма ярыгыннан Мидхәт белән Җәмиләнең парлап чишмәдән су алып кайтканнарын карап, кызыгып тора. Көянтәсен иңенә кундырып, кәз-кәз атлап алдан Җәмилә кайта, аңа ияреп, хатынының уңга-сулга чайкалган артыннан күзен ала алмыйча ире теркелди. Ике кулында ике авыр, «үтерәм» чиләк булса да күзе һаман шунда, язга тагын чишмәдән бәбәй кайтачак диген сүз!

Кызыл күн төпле чалбар кигән адәм Мостафаны онытмады, кичләтеп-кичләтеп шым гына керә дә, Мостафаны ишегалдына чакырып чыгара, алар аулакка – лапас астындагы имән түмәрләренә кунаклыйлар да, озаклап-озаклап нидер гәпләшәләр. Кызыл ыштан сүзгә әвәс, Мостафа аратирә мөгрәп куюдан узмаса да һич гарыкмый, каян сүзен таба, әгъвәли егетне, күз буа. Ул киткәннән соң, Мостафа, бик озак йокыга китә алмыйча, боргаланып ята, йоклап киткәч саташа.

Көзге кичләрнең берсендә, арба ташлап чанага күчеп бетмәгән бер мәлдә, пот-пот балчык ябышкан тәгәрмәчләрен көчкә сөйрәтеп килеп кермәсенме теге егет. Мондый чакта олы кайгы гына йөртә адәм баласын! Керде егет, куна калды, шул кичне генә Халисә аның ГПУ дигән бик хәтәр урында эшләвен белеп калды. Ни йомышы бар икән бу ау этенең аның ирендә?!

Комсомол җыелышлары кайнар, таңгача сузыла, алай да аңа карап Мостафаның үзгәргәне юк. Театр буласы көннәрдә клуб эскәмияләренең аякларын ныгыта, Октябрь, Май бәйрәмнәре җитәрәк урам уртасына, «трибуна» дигән нәрсә корып, аны бик тырышып кызылга буйый, комсомол өмәләренә башлап йөри, кыскасы, Халисәнең тешләк Мостафасы бер көнне «актив» булды да куйды. Иренең кыланышларын һич яратмады Халисә! Сүзгә кергән чакларында, Мидхәт күршесен гел ару мисалга китерде. «Әнә, кеше нинди була ул?.. Вакытында эшеннән кайта, мал-туарын бага, кым-кырыч баласын карарга хатынына булыша!» Район гәзитендә Мостафаның дәү генә сурәте басылып чыккач, булды мондый сүзләр.

(Дәвамы киләсе санда.)

Казан ханлыгы яулап алынганнан соң рус дәүләте тарафыннан алып барылган милли, дини һәм колониаль изү көчәю татарларны Кама елгасының көнчыгыш ярларына һәм Урал буена күчеп утырырга мәҗбүр итә. Әмма XVII гасырның I яртысында ук җирләрне вотчинник буларак яки саклау грамоталары нигезендә беркетү башлана. Элекке Уфа өязе җирләрендә гомер итүче халыкның Казан һәм Себер ханлыкларына, Ногай Урдасына ясак түләп яшәве бүген һәркемгә мәгълүм.

Бөре һәм Стәрлетамак: башкортлаштырылган авыллар

Алар Казан ханлыгы ауганнан соң Казан, Ногай, Себер юллары дип йөртелә, ул җирлектәге волостьларда яшәүче халык «башкорт» дип санала. Алар составына Көньяк Уралда терлекчелек белән күчмә тормыш алып баручы күчмәннәр дә керә. Башкортларның күчмә ырулары 1816 елда үткәрелгән 7 нче җанисәпкә кадәр күршедәге казах халкы вәкилләре белән дә тулыланып тора. Казан өязенең Җөри юлындагы Балтач авылыннан чыккан Бәйрәмхуҗа атлы крестьянның XVII гасырда Уфа өязе җирләренә килеп «башкорт» катламындагы җирбиләүчегә әверелүе, хәтта шунда тархан дәрәҗәсенә лаек булуы турында без күп язлык инде.

«Башкорт катламы» формалашу XIX гасырда да актив дәвам итә һәм ул нигездә татар милләте вәкилләре хисабына тулылана. Аеруча 1855 елгы фәрман буенча элек «Башкорт гаскәре» составына кертелгән барча типтәр, мари, мишәрләрне фәкать «башкорт» дип язу закон көчен алгач, башкортлаштыру хәрәкәте массакүләм төс ала.

Әлеге «мәҗбүри рәвештә башкортлаштыру» темасы хәтта бүген дә мөһимлеген җуймый. Чөнки бик күп Уфа галимнәре халыкның катламын күрсәтүдән качып, типтәрдән яки мишәрдән «яңа башкорт»ка әверелгән төркем булуын инкяр итәргә тырыша, ягъни асыл тарихка хыянәт итә. Ә асылда 1798 елда Башкорт-мишәр полкларын булдыру турында фәрман игълан ителүгә үк, татар һәм типтәрләрне «башкорт катламына» күчерүдә хәрби губернаторлар үзләре дә шактый көч куйган бит.

Архивта тупланган 7 нче ревизия документларына күз йөгертик. Бөре өязенең Ялангач авылы (бүген Балтач районында) халкы моңа кадәр старшина Шәрип Әхмәтов командасына караучы 59 җан иясе булып торган. Әмма 1816 елда бирелгән мишәр Габделҗәлил Мәхмүтовны гаиләсе белән бергә 10 нчы «башкорт» кантонына беркетеп куйганнар һәм әлеге гаилә «башкортлар» исемлегенә кереп киткән.

Ә тарихчы Ә.Әсфәндияров әлеге мисалны искә дә алып тормый, ул «1834 елда Ялангачта 69 мишәр һәм 16 типтәр яшәгән, 1859 елда аларның гомумсаны – 159 га, 1920 елда 719 кешегә җиткән», дип кенә яза. 1816 елдан соң Малмыж өязенең Исмәгыйл авылыннан Ялангачка күчеп килгән 5 лашман гаиләсе (1834 елда гаиләләрдәге кешеләр саны 42 гә җитә) турында искә алып «вакланмый».

Шушы Ялангачта телгә алынган Г.Мәхмүтов исә 1813 елда бүгенге Караидел районындагы Хәлил авылына күчерелә һәм хәрби губернатор фәрманы буенча башкорт катламына языла. Аның гаиләсендәге 13 җан да кушылгач, Хәлил авылындагы «башкортлар» саны 1816 елда – 169 га, 1859 елда 359 га җитә.

Бүген Мишкә районында саналган һәм элек старшина Әхмәт Шәрипов җитәкләгән 4 нче мишәр кантонына буйсынган Мәүлет авылындагы Әбелхәер Зәитовны да 1814 елда Караидел районындагы Бәгәҗе авылы «башкорты» итеп күчерәләр. Ул гаиләсе белән анда Йорт старшинасы, 1813 елда дворян дәрәҗәсе белән олыланган Шәфи Мостафинга буйсына башлый. Старшина Шәфи бер дә начар яшәмәгән, билгеле, аның 20 яшьтән алып 70 яшькә кадәрге 4 хатынга өйләнеп торуы ук шуны раслый. Бәгәҗедәге «башкортлар» саны шулай итеп 145 кешегә җитә.

Бөре районының Туртыш авылында яшәүче мишәр Сәетбаттал Мостафин гаиләсе хәрби губернатор фәрманы буенча 9 нчы башкорт кантонындагы Якуп авылына (Кушнаренко районында) күчерелә. Туртыш авылындагы азанчы Динмөхәммәт Даутовны да шул ук фәрман белән Илек авылындагы җәмигъ мәчеткә күчерәләр. Аларның барчасы да «башкорт» булып исәпләнә башлый. Якуп авылының үзендә моңа кадәр типтәр Әхмәр Габделҗәлилов һәм өч бертуган – Якуп, Вәлиша, Җиһанша Габдуллиннар гаиләсе яшәп яткан була, алары да «башкорт» катламында исәпләнә.

Бүген Краснокама районында исәпләнгән Куян авылында 1815 елда Әгерҗедән күчереп утыртылган 5 кешелек ясаклы татар Габделвәһап Хәбибуллин һәм Ибраһим Дилмөхәммәтов гаиләләре барлыкка килә һәм алар Вятка губернасының Сарапул өязе хуҗалары фәрманы буенча «башкорт» катламына языла. Бу гаиләләр дә өстәлгәч, Бөре өязенә кергән әлеге Куянда «башкортлар» саны 395 кә җитә.

Күргәнсездер, Оренбург губернасының Бөре өязендәге Ялангач, Бәгәҗе, Билгеш, Куян, Туртыш, Хәлил авылларындагы «башкортлар» саны якын-тирәдәге татар-мишәр крестьяннары хисабына арттырыла.

Стәрлетамак өязендә дә «башкорт» милләтенең санын арттыру һаман да шул татар-мишәр хисабына алып барыла. Мисалларга тукталыйк.

Бүгенге Стәрлетамак районының Бүрекәзган авылындагы 2 нче мишәр кантоны җайдагы Мөхәммәтгали Гаделшин Оренбург хәрби губернаторының 1813 елгы фәрманы буенча 9 нчы «башкорт» кантоны составына күчерелә һәм алга таба «башкорт» яугире булып исәпләнә башлый. Шул ук хәрби губернатор фәрманы буенча, Үрге Урал өязендәге 1 нче мишәр кантоныннан Кырмыскалы районындагы (Иске) Җанбәк авылына 10 кешелек Габдерәхим Ситдыйков гаиләсе күчереп утыртыла, алар да кушылгач, 1816 елгы җанисәптә бирелгән 27 хуҗалыкта гомер итүче «башкортлар» саны 136 га җитә.

Шунысын да өстик, 1825 елда Җанбәктәге «башкортлар» саны «чит ил»дән китереп утыртылган Мокътасип Дәүләтбай улы Сабаков һәм Бадел Абызгилдин кебек әсирләр хисабына да арттырыла. Моны Ә.Әсфәндияров та яшерми, әмма «1859 елда авылда 60 ир-ат вотчинник һәм шул ук санда «башкорт» типтәрләре яшәгән», дип кенә йомгаклый. Ә әлеге типтәрләрнең 1855 елгы фәрман буенча, «Башкорт» гаскәрендәге барча типтәр-мишәрләрнең фәкать «башкорт» булып кына санала башлавын искә алып тормый.

Стәрлетамак өязендә 1816 елда уздырылган 7 нче ревизия мәгълүматларына әйләнеп кайтсак, бүген Авыргазы районында саналган Солтанморат авылында (Галимҗан Ибраһимов ватаны) старшина Янышевка буйсынган мишәр командасындагы бертуган Габделгаффар һәм Габделвахит Габделханнановлар 1813 елда Балыклы күл авылына (шул ук Авыргазы районында) күчерелә. Әмма 1816 елгы җанисәптә аларны 7 нче «башкорт» кантоны яугирләре хисабына кушып куялар һәм, әлбәттә ки, моннан ары алар да «башкорт» булып китә. Тик барыбер 1816 елда Балыклыкүл авылында мишәр катламындагы татарлар 135 җан исәпләнә әле.

Солтанморат авылында Йорт старшинасы Исхак Нигъмәтулла улы Янышевка буйсынучы мишәр Тимербулат Бикташев та 1815 елда 9 нчы «башкорт» кантонына күчерелә. Һәм киресенчә: 1812 елда 9 нчы «башкорт» кантонында исәпләнгән старшина Сабит Сәгыйтов, хорунжийлар Габдерәфыйк Габдерәхимов белән Габделкәрим Габделҗәлилов гаиләләре һәм, аларга кушып, Шәмсетдин белән Сиражетдин Зәйнетдиновлар 1813 елда Солтанмораттагы туганнары Тәрҗем Терегулов янына кайтарыла. 1816 елда Солтанмораттагы татар-мишәрләр саны 447 гә җитә.

Шул ук Авыргазы районындагы Исмәгыйль авылында Йорт старшинасы Йосыф Могъсимовка буйсынучы 2 нче мишәр кантонында саналучы Мөдәррис Гобәйдуллин 1816 елда 7 нче «башкорт» кантонына күчерелә һәм, шик тә юк, «башкорт» булып санала башлый.

Бу төбәктә хөкүмәт алып барган «башкортлаштыру» сәясәтенә каршы гамәлләр башкарылу гаҗәп. Әйтик, 9 нчы «башкорт» кантонында саналган Мөхәммәткәрим Мортазин (40 яшьтә) 1813 елда Ибрай авылыннан Исмәгыйль авылына күчерелә һәм янә мишәр булып санала башлый. 1816 елда 33 яшьлек Рәхмәтулла Баишев та, бер кантоннан икенчесенә күчерелеп, мишәрлегенә кабат кайтарыла. Өстәп куйыйк: мишәр катламындагылар белән татарлар арасында никахлашу туктаусыз рәвештә алып барыла, ә менә башкорт белән мишәрләр арасында гаилә кору очраклары бөтенләй юк...

Бүгенге Дәүләкән районына караучы (Иске) Мерәс авылына тукталсак, 1815 елда мондагы халык, хәрби губернатор фәрманы буенча, Илчебай Нурлыбаев, Күлбай Үтәпов шикелле 4 кыргыз гаиләсе хисабына тулылана һәм «башкортлар» хәзер 142 җан булып исәпләнә башлый. Әлеге Мерәстә 1834 елда 84 яшендә дөнья куйган Габдерәхим җирләнә, ә ул – бүген барча төрки дөньяга мәгълүм Габдерәхим Госман улы Утыз-Имәни бит! Ул Әфганстанга ясаган сәяхәтеннән кайтышлый, Мерәстәге кантон башлыгы, 32 яшьлек морза Локман Ибраһимов йортында туктала. Локманның Габдерәхим исемле бертуган абыйсы бик иртәли дөнья куйган була, шушы исем уртаклыгы сәбәпледер, Локман үзеннән күпкә өлкән шагыйрь Утыз-Имәнине якын туганы шикелле кабул итә. Шагыйрьнең 60 яшьлек хатыны Фәтхия Габдерәшит кызын, күп сандагы балаларын һәм оныкларын да «уршак-мин ыруы башкортлары» дип язып куялар. Ягъни Мерәс «башкортлары» сафын кыргызлар гына түгел, сәфәрче шагыйрь Утыз-Имәни дә тулыландыра...

Бүгенге Ишембай районындагы Янурыс (дөресе Җанырыс – «бәхетле җан») авылындагы указлы мәзин Габделхалик Габдерәшитов, мөдәррис Габделкадыйр Габдрәшитов, мөхтәсиб Нигъмәтулла Зөбәйдуллин, алардан тыш янә әллә ничә гаилә (барлыгы 39 җан) 1814 елда Стәрлетамак өязендәге 7 нче «башкорт» кантонының Нигъмәтулла Рәфыйков командасына күчерелә һәм алар да «башкорт» булып йөри башлый.

Элек Хәлил авылында мәзин һәм старшина Габделханнан Солтанморатов командасында мишәр булып торган Сәмигулла Ишморатов та 1815 елда хәзерге Стәрлебаш районындагы Юмахуҗа авылына күчерелә һәм андагы «башкортлар» санын 51 кешенә җиткерә.

Югарыда Бүрекәзган, Җанбәк, Солтанморат, Исмәгыйль, Мерәс, Ногазак, Җанырыс, Юмахуҗа авыллары буенча саналган дәлилләр Стәрлетамак өязендәге «башкортлар»ның нигездә татар-мишәр, ә кайчакларда хәтта кыргыз әсирләре хисабына тулыландырылуын бик ачык исбат итә.

Таһир КӘРИМОВ,
Ш.Мәрҗани ис.Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре.

Чыганаклар:

1.Асфандияров А.З. История сел и деревень Башкортостана и сопредельных территорий. Уфа, 2009.

2.История башкирских родов. Кыргыз. Том 10. Уфа, 2015.

3. Каримов Т.Т. Как марийцы стали башкирами-вотчинниками и продавали земли // Восточное Закамье как один из очагов этногенеза и культуры татарского народа: Материалы Межрегиональной научнопрактической конференции, посвященной 90-летию Актанышского района и 310-летию основания Актаныша. Казань, 2020.

4. Кәрим Т.Т. Җиде бабаңны бел, катайлым: Башкортстанның Бакалы районы Катай авылы нәселләре тарихы: / Таһир Кәрим.Казан, 2020.

5. Кәрим Т.Т. Үткәннәрен бел Катайның: Башкортстанның Бакалы районы Катай авылы тарихы / Таһир Кәрим. Казан, 2018.

6. Кәримов Т.Т. Баулы авылы тарихыннан. Из истории Бавлов //Баллы елга буенда. На медовой реке (на тат. и рус. языках). Казан, 1996.

7. Национальный архив Республики Башкортостан (НА РБ). Фонд И-138. Опись 2. Дело 165, 166, 303, 309, 310, 371, 544, 548, 656, 741, 747.

2011 елны «Карабүрекләр» бизәнгече өчен Илгиз Фазылҗановка International Jewellery Design Excellence Award – Ювелир дизайны Халыкара конкурсының Гран-при бүләге тапшырыла һәм ул «Champion of the Champions» – «Чемпионнарның чемпионы» исеменә лаек була! 2013 елда да әлеге иң дәрәҗәле Халыкара конкурста «Кояш тотылу» комплекты белән ул тагы Гран-при иясе була һәм икенче тапкыр «Чемпионнар чемпионы» исемен яулый. Илгиз Фәрит улы – әлеге конкурста ике тапкыр җиңеп чыккан бердәнбер ювелир.



ДӨНЬЯ ЯУЛАГАН ТАТАР ЗӘРКӘНЧЕСЕ

Аның хезмәтләре «Мәскәү Кремле музейлары» һәм Россиянең Алмаз Фонды коллекцияләрендә күрсәтелә. 2009 елдан алып И.Фазылҗанов әсәрләре Лондондагы «Christie's» аукцион йортларында, Нью-Йорктагы «Bonhams» аукцион йортларында сатыла. Болар – чиксез уңыш! Чөнки бу – авторның әсәрләрен үзе исән чагында ук сату бит. Мондый уңышка тарихта, гомумән дә, гаять сирәк иҗатчы гына лаек була ала.

Татар ювелирының исеме һәм Ilgiz F. бренды күп илләргә мәгълүм! Һәм аның иҗатын бихисап дәүләт коллекционерлары дикъкать белән күзәтә. Ул иҗат юлы башлануына 30 ел тулу уңаеннан «На вершине» дигән саллы китабын нәшер итте, әлеге зәвыклы басмада 30 тау белән бәйле 30 яңа йөзекнең фотолары да урнаштырылган. Әлеге йөзекләр иҗат юлындагы 30 түбәне символлаштыра. Ул – бар дөнья буйлап өч йөз иллегә якын күргәзмә үткәргән гаять тәҗрибәле иҗатчы да!

Илгиз Фазылҗанов 1968 елның 28 мартында Яшел Үзәндә, Мөршидә һәм Фәрит Фазылҗановлар гаиләсендә туа. Зур гаиләдә дүрт ир бала үсә. Илгизнең туганнарының һәммәсе дә – оста куллылар! Әмма рәссамлыкка сәләт – бары тик анда гына.

Ул сынлы сәнгать мәктәбендә, Казан сынлы сәнгать училищесында белем туплый. 1991 елда, борынгы милли традицияләребезгә таянып, милли ювелир бизәнгечләребезне ясый башларга ният кылучылар табылгач, шулар белән берлектә Дүшәнбегә юллана, ләкин Таҗикстанда сәяси болганышлар башланып китә һәм иҗат төркеме ювелирлык сәнгатен тиешле дәрәҗәдә өйрәнә алмыйча, әйләнеп кайта. Шуннан соң яшь рәссам Яшел Үзәндә әлеге һөнәргә үзлегеннән төшенә башлый. 1992 елда «Казан» милли-мәдәни үзәгендәге остаханәсендә Идел буе болгарларының, Казан татарларының тарихи җепкыр ысуллы эшләнмәләрен ясый һәм болгарларның милли традицияләре юнәлешендәге беренче ювелир эшләнмәләре коллекциясен иҗат итә.

1994 елда ук И.Фазылҗанов Исламабадта мөселман дәүләтләре яшь ювелирларының Сәнгати һөнәрчелекнең I Халыкара ислам фестивалендә җепкыр ысуллы, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән Коръән тартмасы, милли хәситә һәм милли беләзек тәкъдим итеп, беренче дәрәҗәдәге Гран-прига лаек була.

1998 елда оста инде Франциядә, Антибта узган Һөнәрчеләр сәнгатенең Халыкара салонында катнаша. Уңышлы иҗаты аны Ilgiz F. халыкара сәүдә маркасын теркәүгә китерә. 2002 елда аның әсәрләре Санкт-Петербургта һәм Мәскәүдә оештырылган күп халыкара конкурсларда җиңү яулый, тамашачылар һәм профессионаллар тарафыннан югары бәяләнә. Декоратив-гамәли күргәзмә кысаларында үткән Италиядәге Татарстан көннәрендә И.Фазылҗанов эшләнмәләрен дә экспозицияләр. Ул Миландагы VII Халыкара һөнәрчелек күргәзмәсендә, Швейцариянең Базель шәһәрендә уза торган Сәгать һәм кыйммәтле эшләнмәләрнең Бөтендөнья күргәзмәсендә катнаша. 2003-2006 елларда Мәскәүдә оештырылган дәрәҗәле конкурслар һәм күргәзмәләр дә аңа бихисап җиңүләр китерә.

И.Фазылҗанов әсәрләре төрле елларда АКШта, Гонконгта узган Халыкара күргәзмәләрдә, Монакодагы Халыкара заманча сәнгать салонында, Токиодагы Халыкара ювелир күргәзмәсендә, Пекиндагы Кыйммәтле эшләнмәләр буенча Халыкара күргәзмәдә, Мәскәүдәге Халыкара ювелирлык өлкәсендәге икътисад форумында күрсәтелә, хезмәтләре Женевада да тәкъдим ителә. 2014 елда аның ювелир әйберләр тупланмасы Россия Гохраны оештырган «Россия, XXI гасыр» ювелирлык сәнгате конкурсының Гран-при бүләгенә лаек дип табыла... Бу талант иясенең бар һөнәри уңышларын бер язма эчендә санап чыгу мөмкин түгел.

Останың әсәрләре – Татарстан дәүләт музейларында, Мәскәү Кремленең Корал палатасында, Эрмитажда, Тарих музеенда һәм Россия, Бөекбритания, Дания, Италия, Чехия, Латвия, Монако, АКШ, Франция, Швейцария, Япониядәге һ.б. шәхси коллекцияләрдә саклана. «Мәскәү Кремле музейлары» карамагындагы Корал палатасы татар ювелирының утыз ике иҗат эшен һәм бер эскизын даими экспозиция өчен сатып ала. Аның ювелир бизәнгечләре Европа аристократларының нәселдән нәселгә күчәчәк кыйммәтле эшләнмәләре булып та санала.

Илгиз Фәрит улының металлда иң аз калынлык куллана алуына таң калырлык, әйтик, витраж эмале техникасында ул 1 мм калынлык куллана. Кайнар эмальле бизәнгечләренең искиткеч катлаулы булуы һәм бу төр иҗаттагы виртуозлыгы өчен останы «Эмаль короле» дип атыйлар. Бүгенге көндә Ilgiz F. бер елга берничә йөз югары дәрәҗәдәге сәнгать әсәре иҗат итә.

Франциянең Cartier һәм Van Cleef & Arpels Ювелир эшләнмәләре йортлары белгечләре милләттәшебезнең иҗатын һәрчак бик югары бәяли. 2018 елда ул французлар чакыруы буенча Ювелир сәнгате мәктәбендә эмаль бизәнгечләр хакында ачык лекция укый, үз иҗат юлы турында сөйли. Әлеге Ювелир йорты музее аның витражлы эмаль ысулындагы бер пар зиннәтле алкасын да сатып ала!

Останың иҗатында техник ысуллар

бихисап һәм ул аларның барсына да үзлегеннән төшенгән. Илгиз Фәрит улы үз кабатланмас стилен булдыруга дистә елдан артык вакыт сарыф иткән. Ювелир сәнгатендәге беренче омтылышлары чорында останың махсус эш кораллары да булмаган, ул аларны үзе ясаган.

Болгар осталары сәнгате стилендә көмештән иҗат иткән иң беренче татар милли алкаларының нәфисләгенә Илгиз Фәрит улы үзе дә сокланып һәм гаҗәпләнеп карый. Чөнки бу алкалар бернинди һөнәри белеме булмыйча торып ясалган бит. Ул көннәр инде шактый еракта калган, хәзерге иҗат исә тирәнтен уйланылган гаҗәеп матур эскизлар аша башкарыла... «Эскизларны һәрчак ясыйм. Остаханәмдә дә, берәр кая барган чакта юлда да... Инде тупланганнары буенча гына да озак вакытлар иҗат итәргә мөмкин булыр иде, шуңа карамастан эскиз ясаудан туктап торганым юк. Аннары шул эскизлары буенча махсус балавыздан модельләр уям. Бизәнгечнең әзер рәвешен уйларымда алдан ук ачык күзаллыйм.

Камил әсәр иҗат итсәм, иҗади ләззәт хисе кичерәм. Бизәнгечләр бик купшы, тоташ бриллиант сибелгән генә була дигән сүз түгел, алар гадилеккә, лаконизмга ия һәм төсләрнең җетелеге ягыннан тынычрак та булырга мөмкин...» – дип сөйли ул үз иҗаты хакында.

Фазылҗановлар гаиләсе 2003 елда Мәскәүгә күченә. Илгиз Фәрит улына ул елларда да бик күп эшләргә туры килә. «Мәскәү Кремле музейлары» дәүләт тарих-мәдәният музей-тыюлыгының генераль директоры Елена Гагарина инглиз, һинд кунаклары белән очрашканда, алар Россиянең берәр танылган ювелиры белән күрешергә теләк белдергәч, генераль директорга башкалада талантлы татар ювелиры иҗат итүен искәртәләр, шулай итеп Елена Юрьевна Илгиз Фәрит улы белән таныша. Аның шедевр әсәрләрен күргәч тә, шәхси күргәзмәсен Мәскәү Кремлендә ачарга тәкъдим итә. 2016 елда И.Фазылҗановның «Драгоценности, вдохновленные природой» шәхси күргәзмәсе дүрт ай буе эшли һәм зур уңыш казана. Күргәзмәне 130 000 нән артык тамашачы карый!

Талант иясеннән илһам чыганаклары хакында сораганда, ул җавабын хәләл җефете Динә, балалары, гаиләсе белән бәйли. Илһамны ул, һәр рәссам кебек үк, әлбәттә, матур табигатебездән дә ала.

И.Фазылҗановның техник яктан гаять катлаулы ювелир әсәрләрендә нинди генә кыйммәтле ташлар юк! Тик шулай да опалларны күбрәк ошатуын искәртеп була төсле... Ювелир әсәрләрдәге төсләр спектры сынлы сәнгатьтәге төсләр белән чагыштырганда күпкә баерак, ә опаллар исә – күп төсмерләр җыйган ташлар...

И.Фазылҗановның «Дөнья түбәләре» йөзекләр сериясен тагы бер кат искә алсак, анда мәгърур Везувий, Арарат, Килиманджаро, Фудзияма, Гималай таулары сурәтләре бар.... Аларның атмосферасы дәһи ювелир иҗатындагы мәгълүм этапларны, омтылышларны, уңышларны чагылдыра.

«Эмаль белән бик очраклы рәвештә генә шөгыльләнә башладым. Аларны миңа махсус эш коралларын сатучы тәкъдим итте. Ә бит моңа кадәр дә мин, рәссам да буларак, эшләнмәләремә төсләр җитмәвен тоя идем. Иҗатта хәтта төсләре күп гасырлар буе сакланачак кыйммәтле ташлар да тиешле эффектка китерә алмаска мөмкин бит... Шулай итеп, 1997 елда бик тә катлаулы эмаль ысулына үзлегемнән төшенә башладым, техник белемем булмаса да, тәҗрибәләр юлы белән бардым. Кайчак: «Мин моны ничек башкарып чыга алдым соң», дип тә уйлана идем. Ювелир сәнгатенең бу юнәлешендәге техник таләпләрне башкача, үземчә генә башкардым һәм бу хәзер дә шулай дәвам итә. Беренче эмаль эшләнмәләремне иҗат иткәндә үк бар да яхшы килеп чыкты һәм мин әлеге ысулны куллануымны дәвам иттем.

Тәүге эмальле бизәнгечләремне 1997 елны, Пуатьедагы Халыкара антиквар салонда французларга күрсәттем. Алар башта ышанмыйча торды: «Ничек инде?! Сез боларны, эмаль кулланып, менә әле генә ясадым, дисезме?!» Ә бер француз журналы хезмәтләремне узган гасырларда ясалган эшләнмәләр дип аңлап: «Менә үзе инде күптән вафат бер талантлы ювелирның Россиядән китерелгән әсәрләреннән күргәзмә ачылды», – дип язды. Аннары ялгышуларын аңлап, миннән озак гафу да үтенделәр», – дип искә ала ул үз әңгәмәләрендә.

Осталар кызыл һәм ал төстәге эмальләр ясарга сирәк алына, чөнки бу гаять четерекле процесс. Технологиясе аңлаешлы, тик кызыл эмальне махсус мичкә куйгач, искиткеч дәрәҗәдәге эчке сиземлек сорала, югыйсә, эшләнмә бозылырга бик мөмкин. Илгиз Фәрит улыннан шулкадәр матур кызыл һәм ал төсләрдәге эмальле бизәнгечләр ничек иҗат итүе хакында еш сорыйлар. Билгеле, ул үз тәҗрибәләрен уртаклаша, башка ювелирларның сорауларына да җаваплар бирә. Аның 2018 елда ук ачылган Ilgiz F. галереясы да – сәүдә максатындагы салон гына түгел. Әлеге галереяда төрле ювелирларның күргәзмәләре оештырыла. Бу сәнгатьтә осталар – меңнәр, ә профессионаллар ягъни бер үк вакытта дизайнер да, ювелир да булганнар – санаулы. Шуңа күрә сәнгать сөючеләр дә әлеге галерея эшчәнлеген үз итә. Илгиз әфәнде яшь иҗатчылар белән очрашулар уздырырга да вакыт таба.

Аның иҗатында үсемлекләр, чәчәкләр белән бәйле шедевр әсәрләр күп. Ул хәтта тигәнәкне, хәтта гади шайтан таягын да камиллек дәрәҗәсенә күтәрде. «Кайбер күренешләргә кешеләр гомумән дә аз игътибарлы. Көндәлек күреп йөргән үсемлек тә бик үзенчәлекле. Әйтик, шайтан таягы үсемлеге мине уникаль «архитектур» төзелеше, « графикасы» белән үзенә җәлеп итә, аны бик тә эффектлы итеп үзгәртеп, заманча бизәнгечкә өстәп ясарга мөмкин!» – дип аңлата әңгәмәдәшем, туган ягы – Яшел Үзән табигатен дә искә алып, һәм ассызыклап әйтеп куя: – Ювелир иҗатында туктап тору, стагнация булырга тиеш түгел!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Гаяз Исхакый һәм Габдрәшит

Сәяси карашлар бәрелеше

Тарихтан билгеле: Гаяз Исхакый һәм Габдрәшит Ибраһимның мөнәсәбәтләре шактый каршылыклы булган, бу хакта шул чор матбугаты һәм архив документлары сөйли. Дөрес, хәзергә бу материаллар бер яклырак, күбрәк Г.Исхакыйның Г.Ибраһимга каршы язган хезмәтләреннән тора. Ул чордагы матбугат битләрендә һәм архив чыганакларында Г.Ибраһимның Г.Исхакыйга каршы язган хезмәтләрен очратырга туры килмәде, бу шәхесләрнең мирасларын өйрәнүчеләрдә дә андый мәгълүматлар табылмады. Бер караганда, Г.Исхакый белән Г.Ибраһим арасында шәхси конфликтлар булмаган кебек, бу ике шәхес арасында аңлашылмаучылык шул чактагы сәяси вәзгыять, милләт тормышына, аның киләчәгенә төрлечә караш белән бәйле төсле. Шул ук вакытта аларның төрле буын кешеләре булуын, икесендә ике төрле холык-фигыль, белем һәм тәрбия икәнлеген, ул чакта җәмгыятьтә тоткан урыннарын да исәпкә алырга кирәк. Г.Ибраһимның Г.Исхакыйдан 21 яшькә өлкәнрәк булуын да онытмыйк.

Шулай итеп, XX гасыр башы, татар яңарышының алтын чоры. Милләтнең алтын баганалары булырлык шәхесләр мәйданга килә, алар арасында Г.Ибраһим һәм Г.Исхакый да бар. 1906 елда, ягъни, Г.Исхакый матбугатта беренче тапкыр Габдрәшит хәзрәтне ачыктан-ачык тәнкыйтьләп чыкканда, аларның җәмгыятьтә тоткан урыннары тигез булмый. Г.Ибраһим Мәдинәдә укып, Коръән-хафизлыкка ирешкән, туган шәһәре Тарада җиде ел имам һәм мөдәррис булган, Уфадагы Диния нәзарәтендә казый вазыйфаларын башкарган, мөфти хаҗда вакытта, хәтта мөфти булып торган, Төркия-Мисырларда инде үзенең беренче дини-сәяси хезмәтләрен, китапларын бастырган, гасыр башында ук Петербургта «Миръат» альманахын чыгарган, шушы елларда татарча «Өлфәт», гарәпчә «Әт-Тилмиз» газеталарын нәшер иткән, инде Төркия, Мисыр, Хиҗаз, Фәләстыйн, Швейцария, Италия, Австрия, Франция, Болгария, Сербия, Япония кебек илләрдә булып, алдынгы карашлы зыялылар белән аралашкан, бай тормыш тәҗрибәсе туплаган, һәм дини, һәм сәяси яктан зур гыйлем туплаган шәхес була. Ул гына да түгел, 1905 елда Г.Ибраһим «Автономия яки Идарәи мохтәрият» дип аталган программа хезмәтен язып бастыра, ул анда милләтнең Россия кысаларында үзбилгеләнү юлларын күрсәтә, соңыннан алар Г.Ибраһим төзегән беренче төрки-мөселман фиркасе «Иттифак әл-мөслимин» партиясе программасында да чагылыш таба. Г.Ибраһим – татарлар, мөселманнар арасында гына түгел, Россия империясендә үз бәйсезлекләре өчен көрәшкән украин, грузин, латыш, поляк, фин, азәрбайҗан сәясәтчеләре арасында да зур абруйга ия кеше, ул Петербургта оешкан «Автономиячеләр» берлеге әгъзасы, демократик карашлы кадетлар партиясендә төрки халыкларның вәкиле була. Г.Ибраһимның ул вакытта Петербургта үз шәхси типографиясе булганлыгын да әйтеп үтәргә кирәк. Габдрәшит хәзрәт бу чорда, һичшиксез, Россия мөселманнарының, шул исәптән, төрки-татарларның да күренеп торган рухи-сәяси лидеры, оештыручы ролен үти.

28 яшьлек Г.Исхакый да бу чорга шактый зур багаж белән килеп җитә. Ул Чистай һәм Казан мәдрәсәләрендә белем алган, Казанда Татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган, Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта, туган авылы Яушырмәдә бер ел имамлык итә, Казанда «Таң йолдызы» газетасына нигез сала, шушы газета аша социалист-революционерларның фикерләрен татарлар арасында тарата. Иң мөһиме – бу вакытта инде Г.Исхакый танылып килүче яшь язучы, татар дөньясын тетрәткән «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәренең авторы була. Аның яшь көчләр арасында бөтен яктан да лидер, башлап йөрүче буларак өлгереп килүен дә әйтергә кирәк.

Бер караганда, бу ике шәхес берничек тә бәрелешмәскә тиеш иде кебек, чөнки көрәш мәйданы, масштаблар төрле, әмма сәясәт аларны маңгайга-маңгай китереп бәрә, чөнки милләт мәсьәләсендә карашлары аерыла. Г.Ибраһим, Россиядә яшәүче бөтен төрки-мөселманнарны ислам байрагы астында берләштереп, үз хокуклары өчен көрәшергә, үз автономия-мохтәриятләрен төзәргә чакырса, Г.Исхакый, ул вакытта социалист буларак, эсерлар партиясенең фикерләрен алга сөрә – татар, рус һәм башка милләт эшче-крестьяннарына берләшеп, самодержавиегә каршы, шул исәптән, татар, рус һәм башка милләт байларына да каршы көрәшкә күтәрелергә чакыра. Ягъни бу юл большевикларга бик якын сыйнфый көрәш юлы була. Әлбәттә, Г.Исхакый соңыннан бу юлыннан баш тарта, милли бәйсезлек идеологы һәм юлбашчысы булып китә, әмма аңа кадәр язучыга төрмә, сөрген газаплары, мөһаҗирлектә тилмерүләр аша үтәргә туры киләчәк әле...

Шулай итеп, Г.Исхакыйның Г.Ибраһимга матбугат битләрендә беренче тапкыр «һөҗүме» 1906 елның августында була, сәбәбе – «Иттифак әл-мөслимин» фиркасенең корылтаена әзерлек белән бәйле. «Иттифак» партиясенең беренче съезды 1905 елның 15 августында, Түбән Новгородтагы Мәкәрҗә ярминкәсе вакытында, Ока елгасында, пароходта уза, икенчесе 1906 елның 23 гыйнварында Петербургта, шәхси квартирада, өченчесе инде кануни рәвештә, хакимиятнең рөхсәте белән, 1906 елның 16-21 августында Түбән Новгородта үткәрелә (А.Ю.Хабутдинов, Д.В.Мухетдинов. Всероссийские мусульманские съезды 1905-1906 гг. – Нижний Новгород. 2005.). Г.Исхакый да, Г.Ибраһим да бу корылтайларның өчесендә дә катнаша, Габдрәшит хәзрәт – оештыручы, шушы партиянең программасын язучы һәм лидеры, ә Г.Исхакый – сулчы-«таңчы» татар яшьләренең башлыгы буларак. Татар яшьләре һәр корылтайда үзләренең социалистик идеяләрен уздырырга тырышса да, Йосыф Акчура, Г.Ибраһим, Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Садри Максуди, Һади Максуди, Исмәгыйль Гаспралы, Галимәрдан Тупчыбашев, Габдулла Апанай, Габдулла Буби кебек танылган шәхесләрдән торган төрки-татар монолитын җимерә алмый. Исеменнән үк күренгәнчә, «Иттифак» ул – бердәмлек, дигән сүз, ягъни империя кысаларында яшәгән төрки-мөселманнар бердәмлеге, баена-фәкыйренә карамастан, шушы шартларда исән калу өчен берләшү мәйданы. Г.Исхакыйчылар ул чакта сыйнфый көрәш тарафдары була һәм мондый берләшүгә кискен рәвештә каршы чыга.

Әйткәнебезчә, «Иттифак әл-мөслимин» фиркасенең ике корылтае рәсми булмаган рәвештә, хакимияттән яшерен үтә, ә өченчесенә рөхсәт алына. Г.Исхакый белән Г.Ибраһим арасында төп каршылык менә шушы «рәсми рөхсәттән» соң башлана. Чөнки бу рөхсәтне алу өчен фирка лидерларына хакимият каршына баш иеп барырга туры килә, ул гына да түгел, Г.Исхакый язганча, алар әле губернаторны «социализм һәм анархизм идеяләренә каршы ислам исеменнән көрәшергә ышандыралар икән»! Ә бу исә турыдан-туры «таңчылар» бакчасына таш ату! Г.Исхакыйның «Мөселман иттифагы» дип аталган мәкаләсе, Чыңгыз» имзасы белән, «Таң йолдызы» газетасында, «Иттифак әл-мөслимин» партиясенең съездына бер көн кала, 1906 елның 15 августында басылып чыга. Ә Г.Исхакый үзе бу турыда рус газетасы «Волгарь»дан укыган була, шунда ук үз газетасында «Иттифак»чыларны пыр туздырып, җавап та бирә. Бу мәкаләсендә ул партия лидерларын «халыкны алдый-алдый бик шомарган шарлатаннар» дип тә, карагруһлар дип тә атый, халыкны сатучылар, ди. Әлбәттә инде, фирка җитәкчеләренең берсе Г.Ибраһимга да каты гына эләгә.

«Ләкин бу көн бу сүзләрне бөтен мөселман исеменнән безнең моңача могтәбәрләремездән саналган Рәшид казыемыз яздырып йөреп, үзенең артыннан тагы икенче берәүгә дә кул куйдырганнардыр. Рәшид казый бөтен татарларның исеменнән әллә нинди ялганнар язып, черегән бюрократлардан ярдәм үтенүенә бер татар да разый булмаган кебек, «мөселман иттифакы» партиясенә йөрүчеләр дә, әлбәттә, үзләренә шул черносотенный эшләрне кабул итмәсләр!» (Гаяз Исхакый. Әсәрләр. 6 том. – Казан, 2005, 67 б.)

● Гаяз Исхакый.

Монда сүз Г.Ибраһим, Галим Максудов һәм Лотфулла Исхаковның, корылтай уздырырга рөхсәт сорап, Россия эчке эшләр министрына язган гаризалары турында бара. Ул заманда патша хөкүмәтенең иң курыкканы – халык арасында социализм идеяләре таралу була, һәм гариза бирүчеләр моннан бик оста файдаланып, җыенның максаты итеп, «мөселманнар арасына таралган социализм, анархизм, зарарлы иттихаде ислам фикерләре белән көрәшергә ысул табу» дип күрсәтә. Әлбәттә, татарлар арасында социалистлар хәрәкәтен башлап йөрүче Г.Исхакый моның белән килешә алмый һәм боларны фаш итәргә кирәк, дип оран сала. «Шуның өчен, «Мөселман иттифакы»ның беренче мәҗлесе шуларның шул кабәхәтлекләрен тикшерү булырга тиеш!» дип яза. (Күрсәтелгән хезмәт, 68 б.) Ләкин бу корылтайда катнашып, дүрт көн рәттән чыгыш ясаса да, Г.Исхакый боларны искә алмый, мөнбәрдән башка темаларны күтәрә.

Әмма съезд үткәннән соң да, Г.Исхакый «Иттифак әл-мөслимен» фиркасен, Г.Ибраһимны тынгылыкта калдырмый, «Таң йолдызы» газетасында алар турында ай буе дистәләгән мәкалә яза. Ул бу юлы инде «Рәшид казыемыз» дип кәнфитләнеп тормый, Габдрәшит хәзрәтнең шәхесен түбәнәйтә торган сүзләр яза. Әйтик, «Таң йолдызы» газетасының 1906 ел, 24 сентябрь санында Г.Исхакый «Кодаң Биктимер» имзасы белән «Гыйззәтле Бикмулла кода!» дип аталган язмасын бастыра. Бу мәкалә сатира жанрында язылган, көлү объекты итеп Г.Ибраһим сайланган. Автор аны «Рәшит әфәнде», «Рәшит казый» дип, фамилиясен күрсәтмичә генә язса да, сүзнең бу могтәбәр зат турында баруы билгеле, чөнки мәкаләдә ул чыгарган газета-журналлар исемнәре белән санап чыгыла. Автор аны мәсләксезлектә, икейөзлелек, ялганчылыкта, куштанлык, авантюристлыкта, хәтта караклыкта гаепли. Әлбәттә, болар берсе дә Габдрәшит хәзрәткә туры килми, әмма сәяси көндәшен ахыргача «манчу» өчен, Г.Исхакый талантын кызганмый.

«Рәшид әфәнде ул сез белгәнчә генә язучы яисә сез суи зан кылганча гына һәр эштән үзенең кесәсенә файда итәргә теләүче милләтче генә түгел! ... Ул сатучы да, ул язучы да, ул өшкерүче дә, ул төкерүче дә, ул бетерүче дә, ул динле дә, ул динсез дә, гакыллы да, тиле дә, ул телле дә, телсез дә. ...Ул елның өч йөз алтмыш көненә өч йөз алтмыш партиягә керә. Көннең егерме дүрт сәгатендә егерме дүрт тапкыр мәсләген алыштыра...», – дип яза «Кодаң

Ибраһим мөнәсәбәтләре

● Габдрәшит Ибраһим.

Биктимер» битлеге астындагы автор. (99 б.)

Әлбәттә, газета укучылар тәнкыйтьләүченең дә, тәнкыйтьләнүченең дә кемнәр икәнен яхшы белгән, соңыннан Г.Ибраһимны яклап язучылар да булган. Әмма инде Габдрәшит хәзрәтнең намусына тиярлек сүзләр әйтелгән, рухы рәнҗетелгән була. Г.Исхакый югарыда телгә алган мәкаләләрендә Рәшит казыйның милләт акчасын үзләштерүче дип тә, карагруһчылар белән эш йөртүче дип тә атый, татар эшчеләрен рус эшчеләреннән аерырга тырышканы өчен дә, социалистларга каршы сөйләгәне өчен дә гаепли. «Кодаң Биктимер» имзасы астында язган мәкаләсендә Г.Исхакый әллә белеп, әллә белмичә, Габдрәшит хәзрәтнең 1904 елда төрмәгә ябылу вакыйгасын бозып аңлата.

«Ул бервакытны сәяси эш белән төрмәгә дә керде, – дип яза Г.Исхакый. – Ләкин аның төрмәгә сәяси эш белән керүе башка кешеләрнеке төсле булмады. Безнең кебек гөнаһлы, простой кешеләрне фатирыннан прокламацияләр, револьверлар тапкан өчен ябалар. Бу тәбәррекне, Истанбулдан чыкканда, чемоданыннан гәрәбәләр, исле майлар чыккан өчен япканнар. Мәкәрҗәдә аның дуслары, әлбәттә, милләтнең хадимнәре, гәрәбәләрне бергә бүлешергә теләүчеләр, «милләт өчен» дүрт-биш йөз сум акча җыеп, үзен аның көчкә түләп алдылар.» (Шунда ук.)

Бу ялгыш фикер, әлбәттә! Г.Ибраһимны ул вакытта төрмәгә ислемай-мәрҗән өчен утыртмыйлар, ә зур, глобаль сәясәттә, Япония-Төркия кебек илләрдә, Россиягә каршы пропаганда алып барганы өчен утырталар! 1904 елның язында, Япониядән кайтышлый, ул Истанбулда туктала һәм монда да милләтебез хокукларын яклау буенча эшчәнлеген башлый. Бу хакта бүгенге тарихчылар менә нәрсә яза:

«Ләкин аның эшчәнлеге рус хөкүмәтендә генә түгел, Госманлы империясе җитәкчеләрендә дә ризасызлык тудыра башлый. 1904 елның 8 августында, аны рус хөкүмәте соравы буенча кулга алалар һәм Русия вәкилләренә тапшыралар. 12 августта Одесса шәһәренә күчерәләр. Г.Ибраһимның кулга алынуы турындагы хәбәр бик тиз тарала, һәм 21 августта инде дуслары һәм теләктәшләренең матди һәм рухи ярдәме белән аны тоткынлыктан азат итәләр.» (Фәрит Галимуллин. Г.Ибраһимның тормыш юлы / Г.Ибраһим. Фәнни-биографик җыентык. – Казан, 2011, 28 б.)

Шунысын да әйтергә кирәк, Гаяз Исхакый һәм аның тарафдарлары Фуат Туктаров, Гали Мамин һ.б. татар социалистлары бер Г.Ибраһимны гына түгел, башка иттифакчыларны да «утка тота». Әйтик, шул ук «Таң йолдызы» битләрендә даими рәвештә Йосыф Акчураны, Фатих Кәрими, Галимҗан Баруди, Габдулла Апанаев, Галимәрдан Тупчыбашев, Тимерша Соловьевларны гел тәнкыйтьләп торалар. Ә моңа кадәр хөрмәт иясе булган Габдрәшит хәзрәт бик тиз татар яшьләренең мыскыллау объектына әйләнә, аның адресына Г.Исхакый башлаган хурлауларны Тукай күтәреп ала, бер-бер артлы аннан көлеп, төрле елларда сатирик шигырь-памфлетларын яза. («Дөнья бу, йа!», «Дәүре галәм», «Ала карга, кара козгын...», «Төрле хайваннар турында бераз мәгълүмат («Хәятел хайваннан»)», «Гаҗәп талантлар», «Хикәя язарга теләүче яңа әдипләргә үрнәк» һ.б.). Монысын инде «буыннар бәрелеше» дип тә аңлатырга мөмкин, чөнки үзәге Г.Исхакый, Тукай, Әмирханнардан торган яшь татар зыялылары «искелек калдыгы» булып тоелган чалмалы буынны кабул итә алмый, ә Г.Ибраһим шул буынның үзәк фигурасы була һәм яшьләрнең бөтен каһәр-мыскыллаулары аның өстенә ява...

Бәлки, шулар сәбәпледер, корылтайдан соң Г.Ибраһим «Иттифак әл-мөслимин» фиркасенең Үзәк комитетыннан чыга. Хәер, алда инде барысын да кара реакция еллары көтә, «Иттифак» партиясенең 1907 елның августына билгеләгән дүртенче корылтае булмыйча кала. 1907 елның мартында Г.Ибраһимны бер елга төрмәгә ябарга хөкем итәләр, газеталарын суд белән ябалар. Габдрәшит хәзрәт, типографиясен сатып, Петербургтан чыгып качарга һәм ил буйлап яшеренеп йөрергә мәҗбүр була, 1908 елның ахырында исә ул, Себер-Урта Азия-Җидесу-Монголия-Кытай-Маньчжурияләр аша, Япониягә үк китеп бара. Бу елларда ул Япониядә, Төркия, Германия, Швейцария һәм Швециядә, Европа-Азия илләрендә мөселманнарның, Россиядә бер хокуксыз яшәүче төрки-татарларның аянычлы хәлләре турында дөньяга хәбәр таратыр, милләтебезнең дәүләт бәйсезлеге идеясен күтәрер. Шушы китүдән, Г.Ибраһим бары тик ун елдан соң гына Россиягә әйләнеп кайтыр, советларга ышанып, халкына бәйсезлек алып бирергә тырышыр, әмма 1921 елның сентябрендә инде большевиклар тарафыннан кулга алыныр, туган шәһәре Тара төрмәсенә ябылыр, могҗиза белән исән калыр һәм инде мәңгегә туган якларыннан китеп барыр... Татарның бөек мөһаҗиренә әйләнер...

Исхакый да 1906 елның ахырыннан башлап, үз илендә кат-кат кулга алыныр, төрмәләргә ябылыр, сөргеннәргә сөрелер, аннан качар, кайда булса да, бер туктамый язар, иҗат итәр... 1917 елгы февраль революциясен сөенеп каршы алыр, үзе әйткәнчә, «сыйнфый байракны милли байракка» алыштырыр, шул елны Мәскәүдә һәм Казанда үткән мөселман корылтайларында башлап йөрер, тарафдарлары белән Милли шура һәм Милләт Мәҗлесен төзер, бу чорда Г.Исхакый чын мәгънәсендә милләт лидерына әйләнер. Әмма хакимияткә большевиклар килгәч, алар тарафыннан милли оешмалар юк ителгәч, совет хакимиятенә протест йөзеннән, 1919 елның башында Г.Исхакый чит илгә китәргә мәҗбүр булыр... Татарның бөек мөһаҗиренә әйләнер... Татарның бу ике бөек мөһаҗире, инде Япониядә, инде мөһаҗирлектә, тагын маңгайга-маңгай бәрелешер...

Милли карашлар бәрелеше

Узган гасырның егерменче-утызынчы елларында (1923-1933) Г.Ибраһим – Төркиядә, Г.Исхакый Варшавада яши. Алар инде икесе дә сәяси эмигрант, мөһаҗир, ләкин Г.Исхакыйдан аермалы буларак, Габдрәшит хәзрәт инде олыгаеп бара, аны тормыш баса, ул инде, яшьлегендәге кебек, зур проектларга тотынмый, ишле гаиләсен алып, Төркиядә үзе нигез салган Бөгредәлек авылына кайтып урнаша. Ә Г.Исхакыйның исә Европада икенче сулышы ачыла, ул җиң сызганып матбагачылык эшенә тотына, берсеннән-берсе яхшы әсәрләр иҗат итә, мөһаҗирлектә яшәгән татарларның милли юлбашчысына әйләнә. Бер караганда, инде аларның юллары аерылган, бүлешер нәрсәләре калмаган кебек, Россия империясе үзе дә, алар хезмәттәшлек иткән кадетлар партиясе дә, эсерларныкы да юк, Г.Ибраһим нигез салган «Иттифак әл-мөслимин» фиркасе дә, Г.Исхакый төзегән Милләт Мәҗлесе дә юк. Әмма Г.Исхакый мөһаҗирлектә дә бер нәрсәгә дә битараф булмый, барысына да өлгерә, күзәтә, бәясен бирә. Һәм ул монда да Габдрәшит хәзрәтнең «гаебен» таба – ул Мәккәдә хаҗ вакытында совет илчесе, кыргыз-казак кешесе Нәзир Түрәколовны озатып йөргән икән! Бу хакта Гарәбстаннан редакциягә хат килә, Г.Исхакый шуның нигезендә, үз исеменнән, «Яңа милли юл» журналының 1931 елгы 2 нче санында (1 февраль) «Коммунист хаҗи» дип аталган мәкалә язып бастыра. Ул советлар илендә диннең кысылуы, мөселманнарның эзәрлекләнүе турында яза, шул ук вакытта совет илчесенең хаҗ кылган булып йөрүен тәнкыйтьли, моны мөселманнарның ышанычын яулау өчен генә эшләнгәнен әйтә. Аларга каршы бергәләп эшләмәгән өчен нигәдер азәрбайҗаннарны да гаепли. Әлбәттә инде, Түрәколов белән бер машинада аны озатып йөргән Г.Ибраһимга да «нык эләгә».

«Большевик үзәгенең ислам дөньясының изге урыннарын үзенең сәясәте өчен шундый мөртәт түрәләреннән пычратуларын ни дип тәфсир итәргә кирәк?.. Моның кыска мәгънәсе: икейөзлелек, ялганчылык! Ләкин андагы мөселман гарәп түрәләренең шул эшкә бармак аша караулары, шул чукынчык Нәзир Түрәколовка, бөтен гомере буе мөселманлыкны капитал итеп, шуннан тамагын туйдырып торган Рәшид казый Ибраһимовның дәлил булып, җитәкче булып йөрүе – кешелек ягыннан да, мөселманлык ягыннан да мәсхәрәлектер. Милләтенә, диненә каршы хөрмәтсезлектер. Болар барысы да – эшнең начар якларыдыр.» (Г.Исхакый. 10 том. – Казан, 2013, 198-199 бб.)

Бер караганда, Г.Исхакыйны да аңларга була, бу елларда ул инде ачыктан-ачык большевизм дошманы, үзенең төп максатын советларга каршы эшләүдә күрә, шунлыктан, бу ил вәкилләре белән элемтәгә кергән, бигрәк тә аларга ярдәм иткән һәркем аның дошманына әверелә. Һәм кул астына тагын Габдрәшит хәзрәт эләгә, ул совет илчесенә хаҗ кылырга ярдәм иткән икән! Икенче яктан караганда, бу гарәп иле ул вакытта инде СССР белән яхшы мөнәсәбәттә була, үзендә аның илчесен тота, аңа мөмкинлек-шартлар тудыра. Мөселман-казах кешесе хаҗ кылырга ниятләгән икән, аның янына бу гамәлнең тәртибен белгән кешене билгеләгәннәр, бу очракта гарәпләр ислам дөньясында абруйлы шәхесе Г.Ибраһимны ярдәм итәргә сораган булырга тиешләр. Монда бернинди дә Г.Исхакый әйткән шпионлык, агентлык, советка сатылу галәмәтләре юк, ә ике мөселманның бергәләп хаҗ кылу факты гына бар. Ә Г.Исхакый моңа бөтенләй башка төрле, сәяси бәя бирә.

Габдрәшит хәзрәт моны укыганмы-юкмы – безгә билгесез, чөнки матбугатта бу турыда аның җавабы күренмәде. Аның каравы, Гаяз Исхакыйның бу мәкаләсенә азәрбайҗан мөһаҗирләре лидеры Әмин бәй Расүлзадә каршы чыга, «Оллу Юрт» газетасының 1931 ел, март санында «Ялгыш юл» дип аталган репликасын бастыра. Ул Г.Исхакыйны мөһаҗирлектә булган бөтен зыялылар белән дошманлашып бетүдә, ихлас булмавында гаепли, моның ялгыш юл икәнен кисәтә, дошманны үз араңнан түгел, Мәскәүдән, большевиклардан, руслардан эзләргә кирәклеген әйтә.

Әлбәттә, Г.Исхакый моңа җавап бирмичә калмый һәм нигәдер тагын Г.Ибраһим темасын күтәреп чыга. Монда инде ул Габдрәшит хәзрәтне «җир белән тигезли», аны авантюрист, дип атый, Төркиядә «Сыйрател мөстәкыйм» дип аталган панисламист газетасын чыгарып, анда гына түгел, Идел буенда да бөтен абруен югалтты, ди, революциядән соң Россиягә кайтып, советларны яклап йөрүен искә төшерә. Хаҗда Түрәкуловны җитәкләп йөргәне өчен, Г.Ибраһим үз кулы белән үзен үтерде, ди. Азәрбайҗан Әмин Расүлзадә дә, казах Нәзир Түрәкулов та онытыла, ә 74 яшьлек себер татары, бохаралы галим Г.Ибраһим дөньяга фаш ителә... Г.Исхакыйның бу җавап мәкаләсен аның томлыкларында очратмадым, архивтан алган русча тәрҗемәсен генә укыдым, ул шулай ук инглиз теленә дә тәрҗемә ителгән. (НА РТ, ф. Р-2461, оп. 1, д. 14, л. 1-16.)

(Дәвамы киләсе санда).

Фәүзия БӘЙРӘМОВА.

Атнаның сәяси мизгелләре

ТУКТАМЫЙ ТОРГАН НИЗАГ

Сәяси атнаның глобаль әһәмияткә ия төп вакыйгасы дип, мөгаен, «Зур җиделек» (G7) илләренең (анда АКШ, Алмания, Бөекбритания, Италия, Канада, Франция һәм Япония керә) 19-21 май көннәрендә Япониядә (Хиросима каласында) үткән саммитын танырга кирәктер. Япония рәислегендә үткән ул чарада бүгенге көннең күп кенә проблемалары үзәккә куелган. Алар рәтенә Кытай-АКШ мөнәсәбәтләрен, дөнья икътисадына бәйле проблемаларны, атом-төш коралсызлануы мәсьәләләрен һ.б. кертергә була (җөмләдән, G7 илләре дөньяда атом-төш коралыннан тулысынча баш тарту тәкъдиме белән чыкты). Бу юлы очрашуга кунак итеп Бразилия, Вьетнам, Индонезия, Һиндстан кебек нейтраль илләр җитәкчеләре дә чакырылган. Әлбәттә, очрашуда зур урын Россия-Украина низагы белән бәйле мәсьәләләргә дә бирелгән. Саммитта исә Украина лидеры В.Зеленский чыгыш ясаган. Ул анда АКШ, Алмания, Италия, Һиндстан һ.б. илләрнең лидерлары белән очрашулар үткәргән. Бу исемлектә мөһим урынны, әлбәттә, аның АКШ лидеры Джо Байден белән очрашуы алып тора. Соңгысы анда Киевнең гадел юл белән тынычлык урнаштырырга омтылуын хуплавы турында әйткән. Ул АКШның Украинага 375 миллион долларлык өстәмә хәрби ярдәм күрсәтәчәге турында да белдергән. Ә G7 илләре Россиягә каршы яңа чикләүләр кертү, Украинага F-16 истребительләре бирү кебек мәсьәләләрдә дә уртак тел тапкан. Йомгаклау документында, Украинага ярдәм күпме кирәк – шулкадәр күрсәтелячәге турында әйтелә. РФ тышкы эшләр министры С.Лавров G7 саммитын Мәскәү һәм Пекинны икеләтә тыюга корылган дип бәяләгән.

Ә Россия-Украина низагы төрле формаларда дәвам итә. Әйтик, 22 майда Украинадан диверсантлар төркеменең кабат Россия территориясенә (бу юлы инде Белгород өлкәсенә) үтеп керүе мәгълүм булды. Соңрак исә аларның чик буендагы Грайворон округына танк вә бронемашиналарда керүе һәм авылларны утка тота башлавы ачыкланды, яраланучылар булуы хәбәр ителде. 23 майда гына РФ Саклану министрлыгы диверсиянең туктатылуы, 70 тән артык террорчының юк ителүе, калганнары Украинага кысрыклап чыгарылуы турында белдерде.

Инде атнаның кайбер башка сәяси вакыйгаларын да санап үтик. Дәүләт Думасы хәрби хәл режимы чорында да сайлауларны үткәрүгә тәэзтмә керткән. Үзәк сайлау комиссиясе Бердәм тавыш бирү көненең логотибы итеп «V» хәрефен билгеләгән. ЕСның тышкы сәясәт башлыгы Жозеп Боррель оешманың тиздән Украинага F-16 истребительләре җибәрә башларга да әзер булуы турында әйткән. Саклану министрлыгы 21 майда Артемовск каласы азат ителүе турында белдерде. Әмма Украина президенты В.Зеленский бу шәһәрнең Россия контролендә күчеп бетмәве турында әйтте. Әрмәнстан лидеры Н.Пашинян Таулы Карабахны Азәрбайҗанның бер өлеше, дип танырга әзер булуы турында әйткән.

Фоат УРАЗАЙ.

Үзәктә – туган ягы,

Хисаметдин Исмәгыйлев иҗатына күзәтү

Зур елгалар чишмәләрдән башланган кебек, иҗат кешесенең дә чишмә башы була. Башкортстанның шифалы туфрагында туып үскән язучы Хисаметдин Шәрәфетдин улы Исмәгыйлевнең (1953) дә иҗатының чишмә башы – халкыбызга бик күп талантлар, күренекле шәхесләр биргән Эстәрлебаш төбәге. Анда туып-үскән язучы-шагыйрьләр гасырлар дәвамында иҗатлары белән татар әдәбиятына саллы өлеш кертә.

● Бөтендөнья татар конгрессының VI съездында: (сулдан уңга) А.Х.Локманов, Н.Ш. Насыйбуллина, Х.Ш.Исмәгыйлев. 3 август 2017 ел, Казан.

Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укыган һәм халыкка мәгърифәт нуры тараткан күренекле шәхесләр бик күп. Габдерәхим Утыз Имәни (1754-1834), Гали Чокрый (1826-1889), Мифтахетдин Акмулла (1831-1895), Гали Рафикый (1890-1944), Төхвәт Янәби (1894-1938) шигырь һәм поэмаларында белем, акыл, кешелеклелеккә дан җырлап, әхлакый камил шәхес образын тудырса, Әбелмәних Каргалый (1782-1826), Һибатулла Салихов (1794-1867), Шәмсетдин Зәки (1825-1865) урта гасыр дини-суфичылык әдәбияты традицияләрен дәвам итә.

XX йөз башында мәгърифәт үзәге туздырылу, кыйммәтле язма ядкәрләрнең юк ителүе, халыкның иҗади көченә зыян китерә. Совет хакимияте урнашу дәверендә әдәбият сүнүгә йөз тота. Яңа идеалларга дан җырларга, элеккеләрен фаш итәргә әзер булган язучылар буыны күренми. Әмма XX йөзнең икенче яртысында әдәбият мәйданына Зиннәт Галимов (1922-1983), Фәйзи Гомәров (1926-2002), Равил Шаммас (1930), Зәки Зәйнуллин (1933-2021), Әдхәт Синугыл-Куганаклы (1935-2004), Рәфкать Рысаев (1939), Равил Гөзәеров (1942-2021), Хисаметдин Исмәгыйлев (1953) килә. Алар татар халкының мөһим ихтыяҗларына җавап бирүгә, рухи тормышны агартуга зур өлеш кертеп, иҗатларында милләт тарихына, кешенең җәмгыятьтәге урынына һ.б. фәлсәфи фикерләргә киң урын бирә. Ә.Синугыл (Куганакбаш), З.Зәйнуллин (Эстәрлебаш), Р. Гөзәеров (Өч-Әсән) Башкортстан җирлегендә туып, иҗат биографиясен Казан, Үзбәкстан, Кырым, Украина, Латвия, Казахстан белән бәйләгән шәхесләр. З. Галимов (Бузатбаш), Ф.Гомәров (Хәлекәй), Р. Шаммас (Хәлекәй), Р. Рысаев (Тәтер-Арслан), Х.Исмәгыйлев (Гөлем) – Башкортстанның үзендә яшәп иҗат итүче әдипләр. Аларның иҗатын колачлап, чорнап алган тема – туган җиргә дан җырлау. Һәркайсы үзгәрешләрне тоеп, борчылып, үз йөрәге аша кичереп яши. Башкортстанда 1996 елдан башлап нәшер ителүче «Тулпар» журналы, шулай ук, «Кызыл таң» һәм «Өмет» газеталары аларның повесть-хикәяләрен тәкъдим итеп, каләм әһелләрен киң мәйданга чыгара.

Хисаметдин Исмәгыйлев 1953 елда Эстәрлебаш районының Гөлем авылында туа. Туган авылында башлангыч мәктәпне, соңыннан Әмир, Эстәрлебаш мәктәпләрен тәмамлый. 1970 елда Стәрлетамак ветеринария техникумына укырга керә. 1971-1973 елларда ракета гаскәрләрендә хезмәт итә. 1975 елдан Уфадагы авыл хуҗалыгы институтында белем ала. 1980 елда Бәләбәйдә баш ветеринар табиб булып эшли. 1983 елдан Стәрлебаш районы Турмай авылында яши, үзе сайлап алган язучылык өлкәсендә ихлас күңелдән бирелеп эшли. Аның иҗат дөньясын, язмышын чагылдыручы символ – авылдашлары. Язучының кайсы гына әсәрен алып карасак та, ул туган ягын, аның табигатен, якты күңелле кешеләрен тасвирлап кына калмый, иҗади колачы белән географик киңлекләрне иңли. Әсәрләренең сюжеты Әфганстан, Пакьстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Азәрбайҗан илләрен колачлый. Әфган сугышында катнашкан татар егетләре, Таҗикстан якларына чыгып китәргә мәҗбүр булган татарларның тормышын киң планда яктырта.

Аның беренче «Явурай» хикәясе «Тулпар» журналында 2001 елда басыла. Тормыш сынауларына дучар булган кешеләр язмышын тасвирлаган иҗат җимеше булачак язучыга уңышлар алып килә. Татар матбугатында 50дән артык хикәя, дистәдән артык повесть дөнья күрә. 2013 елда Уфа китап нәшриятында «Зимагурлар» исемле беренче китабы басылып чыга. 2021 елда «Казан утлары» журналы Хисаметдин Исмәгыйлевнең «Никах» («Әфган таулары») дип исемләнгән китабын нәшер итә. Бу китапта урын алган «Никах», «Мин – Абрек» әсәрләре укучыга реаль тормыш вакыйгаларын тасвирлавы, авторның үзенең күргән-белгәннәренә бәйле булуы белән дә кызыклы. Монда мәхәббәт, тормыш дулкыннарында сыналган ир-ат язмышы тасвирлана. Китапка кергән ике әсәргә дә хас булган иң беренче билге – алар бик тә мавыктыргыч һәм тыгыз сюжетка ия.

Х.Исмәгыйлевнең эчке дөньясы, үзенең кем икәнлеге, нинди икәнлеге ул язган әсәрне укыган чагында сизелә. Каләм иясе үз күзләре белән бик күп гыйбрәтле һәм тетрәндергеч вакыйгалар күрә, шулар белән тәэсирләнә – аның хәтерендә онытылмаслык һәм үзенчәлекле бик күп язмышлар яши. Х.Исмәгыйлевнең иҗади стиле – ул ачык тасвирламаларга һәм образларга бай. Язучыга хас бу үзенчәлек хакында Д.Булатова беренчеләрдән булып «Иҗатында халык гаме», «Без сезнең белән көчле» [1:39] исемле мәкаләләрендә уңай фикерләр әйтә, «Зимагурлар» исемле повестьлар җыентыгына көчле бәя бирә.

Х.Исмәгыйлев прозасында эзлекле рәвештә тематиканы һәм эмоциональ якларны баету өчен фольклор алымнары оста файдаланыла. Очраклы вакыйгалар тәэсирендә геройлар язмышының көтмәгәндә кискен борылыш алуы әсәрләрдә мажаралылык тудыра. Аның «Фәйзулла» повестендә төп геройны язмыш Таҗикстанга илтеп ташлый, «Су анасы» хикәясендә тыныч кына көн итеп яткан персонаж, күрше авылга барып мажарага тарый, «Сак белән Сок» повесте герое Сахалин ярымутравында хезмәт итүче улының хәлен белергә баргач, гаҗәп хәлләргә очрый, Япония җиренә кадәр барып чыга. «Калымчы Җәүдәт» повесте герое – Җәүдәт Әфганстан, Үзбәкстан җирләрен гизә. Җәүдәт Үзбәкстанга җизнәсен җирләргә барганда, вокзалда сатып алынган сигарет тартканнан соң, мажарага тап була. Язучының «Зимагурлар» повесте алтын прискасыннан качкан Басурман һәм Мансур язмышларын бәян итә. «Ачы алма»повестенең үзәгендә дә чит җирдә яшәүче герой язмышы тасвирлана.

Х.Исмәгыйлев хикәя, повесть жанрларына өстенлек бирә. Аларда тел чаралары эстетик һәм әдәби мотивка нигезләнеп бирелә, артык материал, очраклы сүзләр

авылдашлары

● **Х.Исмәгыйлевнең 70 яшьлек юбилее уңаеннан уздырылган чара кунаклары. 4 март 2023 ел, Эстәрлебаш.**

кулланылмый. Автор үз фикерен яшерен символларга төреп бирми, ә кешедә намус хисләрен уятып, аңлаешлы телдә җиткерә. Бу омтылыш һәркемне үз намусы белән күзгә-күз очраштыра, гаделлек җиңгән мизгелне күзалларга ярдәм итә.

Х.Исмәгыйлев халыкның сөйләм теле мөмкинлекләрен уңышлы кулланып, табигатьтән алынган образлар, детальләр характерларның күңел дөньясын аңлауда ачкыч дәрәҗәсенә күтәрелә. Сәнгатьтә рухи күтәренкелек автордан аеруча интенсивлык, әдәби тәэсирлек чараларын мул куллануны таләп итә. Бу юнәлештә Х.Исмәгыйлев халык сүзенә, аның сөйләү стиленә зур әһәмият бирә.

Халык тормышының үзенчәлекләрен күрсәтү, милли колорит тудыру, милли характерны ачу ягыннан Х.Исмәгыйлев хикәяләрендә һәм күләмле әсәрләрендә башка милләт вәкилләре тормышы киң яктыртыла. Әсәрдәге образлар, аерым вакыйгалар әдип тормышы белән турыдан-туры бәйле. Ул белгән, аралашкан кешеләр повесть геройларының прототиплары булып китәләр. Язучы чуаш халкын якыннан белгәнгә аларга хас күркәм сыйфатларны ачып бирә. Образларның тормышчан булуы, чуаш халкының җылы мөнәсәбәте «Явурай» хикәясен яратып укыла торган әсәрләрнең берсе итә.

Х.Исмәгыйлевнең әдәби геройлары – кыю тормыш позициясенә, югары омтылышка ия затлар, гаделсез шартлар белән көрәш мәйданында үз максатларына омтылып яшиләр. Мисалга, «Торналар» хикәясе кешенең яшәү мәгънәсе, максат-омтылышлары турында уйланырга чакыра. Бу әсәрдәниләр бәян ителә соң? Әсәр ныклы сюжетка, эзлекле вакыйгалар чылбырына корылган. Тематик яктан якын килсәк, «Торналар» – реаль әсәр, анда яктыртылган төп тема – туган якка кайту. Татарларда борынгыдан ук торнаның килүе яхшы күренеш дип санала, мул уңыш яисә кешеләр тормышында уңай вакыйгалар вәгъдә итә. Әсәрдә мифологик башлангыч төп сюжет линиясен дә гомумиләштерә.

Х.Исмәгыйлев иҗатында гыйбрәтле язмышка дучар булган шәхесләргә багышланган әсәрләр зур урын алып тора. Ул анда укучыга олы чынбарлык хәлләрен бәян итеп, үз язмышындагы фаҗигале мизгелләргә дә басым ясый, моның белән ул Россиядә барган сәяси вакыйгаларның сәбәбен һәм мәгънәсен ачарга, аларның аерым кешеләр язмышына йогынтысын күрсәтергә тели. Х.Исмәгыйлев әсәрләренең З.Зәйнуллин әсәрләре белән аваздаш якларын да күрергә була. Кош, ат образларына, географик атамаларга киң урын биреп, алар икесе дә бер төбәктә яшәүче халык тормышын, гореф-гадәтләрен, яшәү рәвешен сурәтлиләр, гомумдәүләт үзгәрешләренә карашларын белдерәләр. Ватанпәрвәрлек һәм үз халкы белән горурлык хисләре уяталар. Эстәрлебаш кебек тарихы якларда туып үскән язучыларның дөньяга карашы да, кабул итүе дә, сурәтләп бирү алымнары да аерыла. Үз язмышы белән бәйле, ягъни аларның автобиографик характердагы әсәрләрендә образлар системасы төрле компонентларны колачлый. Аларда фольклордан килгән ярым мифик образлар да, матур әдәбиятта архетипка әйләнгән образлар да гәүдәләндерелә. Иҗатларында яктыртылган образларның һәркайсы әдәби дөньяны баетырга хезмәт итә.

Иҗат итү заманнары төрле булуга карамастан, Эстәрлебаш әдипләрен берләштергән уртак яклар: халык эшенә бирелгәнлек, халыкчанлык, уртак Ватанны тою хисе, милләтнең киләчәген кайгырту. Кечкенәдән үк авыл тормышының, авыл табигатенең гармониясен үзенең җанына, күңеленә, рухына сеңдереп үскән, Хисаметдин Шәрәфетдин улының да тормыш-яшәешенең максаты эш-хезмәтендә, аны иҗади һәм нәтиҗәле алып баруда күренә.

Нуридә НАСЫЙБУЛЛИНА,
филология фәннәре кандидаты,
Г. Ибраһимова исемендәге Тел,
әдәбият һәм сәнгать институтының
өлкән фәнни хезмәткәре.

Айга карап

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

27 май (шимбә). ***Зөлкагдә аеның 7 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында,11.08 сәгатьтә калка, 2.12 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 16.55 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин.

Солы сихәте

Солы организмнан агулы матдәләрне куа һәм калкансыман биз эшчәнлеген җайга сала. Аны чәй урынына пешереп эчсәң, организмнан шлакларны чыгара. Куе итеп төнәтелгән солы сыгынтысында киҗе-мамык тукыманы чылатып киптерү һәм атна буе шуны муенга бәйләп яту калкансыман биз эшчәнлеген нормальләштерә.

28 май (якшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 8нче көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 12.26 сәгатьтә калка, 2.17 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 16.57 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Алоэ мае

Үкчә һәм учлардагы озак төзәлми торган җәрәхәтләрдән котылу өчен, алоэ согы һәм балык маен тигез микъдарда кушалар да, тукыма кисәген чылатып, чатнаган яра турысына компресс куялар. Сыек булса, бераз он кушалар. Компрессны алгач, урынын юмыйлар, ромашка төнәтмәсе белән сөртеп, крем сылыйлар.

29 май (дүшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 9нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,13.43 сәгатьтә калка, 2.22 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.00 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уянырга мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

Гемоглобин микъдарын арттыру

100 әр грамм чөгендер, анар, кишер, алма сокларына 50 грамм бал кушып, суыткычта саклыйлар, көненә 3 тапкыр 2 шәр аш кашыгы кабалар. 3 ай буе һәр айда 10ар көн дәваланалар.

30 май (сишәмбе). ***Зөлкагдә аеның 10 нчы көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында,15.01 сәгатьтә калка, 2.27 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.02 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Аденоидлардан котылу

2 төймә мумиены 5 аш кашыгы җылы суда эретәләр, һәр борын тишегенә 2шәр тамчы тамызалар. Беренче 10 көндә 4-5 тапкыр салалар, аннан соң 7 көн туктап торалар да, кабат дәвалананалар. Шулай 3-4 тапкыр кабатлыйлар.

31 май (чәршәмбе). ***Зөлкагдә аеның 11 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 16.22 сәгатьтә калка, 2.34 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.05 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Гайморитган – әрекмән

Апрельдән майга, августтан ноябрьгә кадәр арада әрекмән тамырларын казып алып, яхшылап юалар, турыйлар. Карасу төстәге шешәгә салып, өстенә хуш исле көнбагыш мае агызалар, бөкесен тыгызлап ябып, караңгы урында 2 атна төнәтәләр, аннан соң сөзеп, суыткычта саклыйлар, кулланыр алдыннан яхшылап болгаталар. Мамык кисәген әрекмән маенда чылатып, борын тишекләренә 10-15 минутка куялар. Көненә 5 тапкыр кабатларга ярый. Мондый май томауны да тиз дәвалый.

1 июнь (пәнҗешәмбе). ***Зөлкагдә аеның 12 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында,17.48 сәгатьтә калка, 2.43 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.08 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Баллы битлек

Бит тиресе шома һәм сәламәт булсын өчен, атнасына 1-2 тапкыр мондый битлек ягарга кирәк. Аз гына балны бит тиресенә (күз тирәсенә тимичә) сөртәләр дә, бал бармакларга тулысынча җыелып беткәнче, җиңелчә суккалап, массажлыйлар.

2 июнь (җомга). ***Зөлкагдә аеның 13 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 19.16 сәгатьтә калка, 2.56 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.10 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Печенье

220 г он, 100 г атланмай, 1 аш кашыгы бал, 60 г шикәр, 1 чәй кашыгы камыр көпшәкләндергеч, бер чеметем тоз кирәк. Он, тоз, камыр көпшәкләндергеч, 50 г шикәрне кушып болгаталар. Шуңа салкын атланмай кисәкләрен салып, кул белән уалар. Бал өстәгәч, ул тиз арада йомшак, үзле камырга әйләнергә тиеш, әгәр инде җыелмаса, бер-ике кашык бик салкын су кушарга була. 12 кисәккә бүлеп, кечкенә йомарламнар укмаштыралар да, калган 10 г шикәрдә әвәләп, пергамент кәгазе җәелгән табага бер-берсеннән ара калдырып тезәләр – алар җәелеп китәчәк. 180 градуслы газ мичендә 30 минут пешерәләр, асты көеп китмәсен өчен, 15 минуттан соң гел ачып карарга кирәк.

Көнчелек – гөнаһлар башы

Гөнаһларның әүвәле, ягъни башы, башлангычы бар. Көнчелек адәм балаларының башка гөнаһларының башы булып тора. Гайбәт сөйләү, телне тыймау, начар сүзләр әйтү, утынны ут ашаган шикелле, изге гамәлләрне ашап бетерергә мөмкин. Урынсызга бәндәне рәнҗетсәк, урынсызга кешене үпкәләтсәк, аның гамәл дәфтәренә безнең бер яхшылыгыбыз күчә, йә булмаса, тегеңадәмнең бер яманлыгы безнең гамәл дәфтәренә күчә. Көнчелек тә – нәкъ шушындый яман гадәт. Ул да безнең изге гамәлләребезне юкка чыгара. Көнчелек изге гамәлләребезне генә түгел, безнең үзебезне дә юкка чыгара ала. Сәламәтлегебезне ашап бетерә. Китапларда адәм баласының гомерен бурычка алу, үлгән кешенең йөзен карау, сәдака алу, авыру һәм көнчелек кыскартыр, диелгән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләм: «Минем өммәтемдә дә өч төрле кимчелек бар. Алар әле һаман йолдыз гыйлемнәре белән шөгыльләнәләр, алар төрле шомлануларга, ырымнарга да ышаналар, аларның күңелләрендә көнчелек бар», –диде. Нәфес булган кешедә көнчелек, әлбәттә, булмый калмый. Әмма иманлы кеше үзенең иманы, гыйлеме белән шушы көнчелекне тыеп торырга тиеш. Аның әрсезләнеп, авыруга әйләнүенә юл куймау зарур. Авыруның кечкенә генә билгеләре сизелә башласа, без табибка барабыз, дарулар эчәбез, авыртуны басарга тырышабыз. Көнчелек тә – шундый чир. Бездә нәрсәгәдер шундый борчылу, көнчелек бар икән, тизрәк тәһарәт алырга, намазлар укырга кирәк, алай итеп тә баса алмасаң, ураза тотарга һәм Аллаһ Тәгаләдән күңелеңдәге шушы чирне чыгаруны сорарга кирәк. Чөнки, әйткәнемчә, көнчелек Аллаһ Тәгалә безгә әманәт итеп биргән сәламәтлегебезне дә бетерүгә сәбәп булып тора.

Дөнья, җаннар яралтылганнан соң, Аллаһ Тәгалә балчыктан адәм баласын яралтты, нурдан фәрештәләрне, уттан җеннәрне яралтты. Һәм шушы балчыктан яралтылган адәмне Аллаһ Тәгалә бөтен нәрсәдән өстен куйды.

Ул үзе яралткан бар мәхлукатка, бөтен җан ияләренә мөрәҗәгать итеп, кешегә сәҗдә кылырга кушты. Шушы вакытта бер Иблис кенә сәҗдә кылмады. Ул адәм баласыннан көнләште. Мин уттан яралтылган килеш, ничек итеп, балчыктан яралтылган кешегә сәҗдә кылыйм, диде. Шуның өчен ул Аллаһ Тәгаләнең ләгънәтенә тарыды. Көнчелек Иблисне шушы хәлгә төшерде. Бу – дөньяда эшләнгән беренче гөнаһ булды. Һәм бу гөнаһ көнчелек нәтиҗәсендә.

Икенче гөнаһ җирдә эшләнде. Ул да көнчелек нәтиҗәсендә булды. Кабил белән Һабил, Аллаһ ризалыгы өчен дип, корбан чалдылар, Һабилнең корбанын Аллаһ Тәгалә кабул итте, Кабилнекен кабул итмәде. Кабилнең корбаны начар сыйфатлы иде. Һабил Кабилгә, күңелендә бозыклык йә үзендә хәрам булган кешенең догасын, корбанын Аллаһ Тәгалә кабул итми, диде.

Кабил бу хакта: «Минем күңелемдә бозыклык бардыр, мин хәрамга да катышамдыр, шунысыннан тыелырга кирәк, пакьләнергә кирәк», – дип уйланырга тиеш иде. Әмма ул, Һабилнең кабул ителгән корбаныннан көнләшеп, аны үтерде. Җир йөзендә беренче гөнаһ та менә шулай көнчелек нәтиҗәсендә булды. Без, адәм балалары, иманлы кешеләр, үз-үзебезне шушы көнчелек, хөсетлек дигән чир белән бимазаламаска, аны тыеп торырга тиеш. Басуны чүп үләне басса, аны утап торалар. Адәм баласы да үзен көнчелектән арындырырга тиеш.

Кеше биш тапкыр намазын укымаса, күңелен кирәкмәгән уйларга юнәлтеп, көнчелеккә бирелеп, үзен-үзе бетерергә мөмкин. Әмма аның намазы рияидан түгел, ихластан, чын күңелдән булырга тиеш. Шул чакта гына ул көнчелектән шифага әйләнер.

Иманнарыбызның зәгыйфь булуы канәгатьсезлеккә китерә, бездә хөсетлекне уята. Без кешедән күпсенәбез, үзебезнеке җ әзсенәбез. Аллаһ Тәгалә әйтте: «Кем гамәлне әзрәк кылса, шайтан аның күңеленә вәсвәсә салыр, байлыгы таулар хәтле булса да, аның күңеленә аз булып күренер. Ризыгы таулар хәтле булса да, бетәр кебек тоелыр һәм ул канәгатьләнү тапмас. Хөсетлек, көнчелек – күңел хастасы», – диде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм: «Ялкау кешенең дусты булмас, ялганчы кешегә ышанучы булмас, көнче кешенең күңеле тыныч булмас», – дигән.

Мал-мөлкәтле бер кешедән көнләшәбез икән, димәк, без Аллаһ Тәгаләнең бу кешегә бирүеннән көнләшәбез булып чыга. Бер сәхабәдән: «Син кешеләрдән көнләшәсеңме?» – дип сораганнар. «Нишләп мин кешеләрдән көнләшим? Берәүнең байлыгы күп, ул рәхәт яши, – дип көнләшер идем, бәлки, бу байлык аны җәһәннәмгә алып баручы, тәмугка алып керүче байлыктыр. Шушы кешегә тәкъдирләнгән тәмуг өчен мин аннан көнләшимме? Йә булмаса, берәүнең гамәлләре аны җәннәткә алып бара торган булса, Аллаһ Тәгаләнең бу кешегә биргән нигъмәтеннән күпсенимме?» – дигән.

Берәүдән күпсенсәң, Аллаһ Тәгалә үзеңнекен юк итәр. Бу кешегә гамәлләр өчен җәннәт насыйп булып, без аны күпсенәбез икән, димәк, безнең үзебезгә насыйп булырдай җәннәтне югалтуыбыз бар, Аллаһ сакласын.

Бу – сынау дөньясы. Аллаһ Тәгалә дәрәҗәне дә, байлыкны да безгә сынау өчен бирә. Ул берәүгә байлык белән сыный икән, моңардан иманлы адәм һич көнләшмәскә тиеш.

Йә Раббым, нинди яхшылыклары өчен шушы бәндәңә нигъмәтләр бирдең, миңа да изге гамәлләр кылып, шушындый дәрәҗәләргә, нигъмәтләргә ирешергә насыйп кыл, дип Аллаһ Тәгаләдән сорарга кирәк. Менә шулай итеп сорау көнләшү булмый. Изге гамәлләр кылуда кешенең көнләшүе дөрес санала. Әйтик, берәү күпкүп итеп намазлар укыса, иртә кич Коръән укыса зикердә утырса, икенче кеше: «Мин нишләп бу кешедән калышам әле, ул җомга намазына йөри, мин дә аңардан калышмыйча, җомгага йөрим әле, ул биш вакыт намаз укый, мин дә укыйм әле, бу кеше ураза тота, мин дә аңардан ким түгел, мин дә ураза тотыйм әле», – дип көнләшсә, мондый көнләшү һич гөнаһ түгел. Без күңелебездән көнләшеп, бер кешегә начарлык теләп йөрсәк, аның байлыгы бетүен теләсәк, яки аның сәламәтлегеннән көнләшсәк, болар Аллаһ Тәгаләгә билгеле. Яманлыкны язып баручы фәрештә безнең кылган начар гамәлләребезне генә түгел, ә уйлаган яман фикерләребезне дә дәфтәренә теркәп бара. Шул гамәлләребез өчен җавап бирергә туры киләчәк.

Шуңа күрә Аллаһ Тәгалә барчабызның да күңелләренә сабырлыклар биреп, Үзе кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә насыйп итсә иде. Көнчелегебезне тыя алмыйча, иманны зәгыйфьләндерә торган гамәлләрне эшләмәскә Аллаһ Тәгалә безгә сабырлыклар бирсә иде.

99 шарты

Бервакыт падишаһ вәзиреннән:

– Нишләп минем хезмәтчем миннән бәхетлерәк икән? Ул бит ярлы, ә мин падишаһ, байлыгым дөньяга җитәрлек, ә җан тынычлыгым юк, – дип сораган.

– Падишаһым, сез аны «99 шарты» белән сынап карагыз.

– Нәрсә соң ул «99 шарты»?

– Төнлә аның ишеге төбенә 99 мең сум салынган янчык куегыз. Янында «Синә бүләккә 100 мең» дигән язу да калдырыгыз. Ишеккә шакыгыз да шуннан соң нәрсә булганын читтән генә карап торыгыз.

Падишаһ шулай эшләткән дә. Хезмәтче янчыкны алып, акчаны санап карагач, әйтеп куйган:

– Бер мең кайда? Бер меңе житми, кайдадыр шунда төшеп калган ул.

Хезмәтче бөтен гаиләсе белән шул җитмәгән, югалган бер меңне эзләргә чыккан. Төне буе эзләгәннәр. Таба алмагач, хезмәтченең ачуы чыккан. Элек сабыр булса, хәзер ул хатынына, балаларына җикеренгән. Йокысы качкан, төне буе шул югалган бер меңе турында кайгырып чыккан. Иртән дә кәефе булмаган.

Падишаһ янына хезмәтенә дә ул йокысызлыктан шешенгән кыяфәте белән, кәефсез килеш килгән. Йөзендә елмаюның әсәре дә булмаган. Канәгатьсезлеге ерактан ук «кычкырып торган».

Падишаһ менә шунда «99 шарты»ның нәрсә икәнен аңлаган да инде. Адәм баласы Аллаһ Сөбханәкә вә Тәгалә безгә бүләк итеп биргән 99 бәрәкәтне оныта да, гомер буе шул җитеп бетмәгән малны эзли. Кеше үзенә насыйп булмаганны эзли, тик шуны аңламый. Татарда «Насыйп мал тешеңне сындырып керә» дигән мәкаль дә бар. Аллаһ Тәгалә тарафыннан сиңа бирелгән мал, телисеңме-теләмисеңме, барыбер синеке булыр. Насыйп булмаса, тешең белән җир казысаң да, сиңа тәтемәячәк. Шөкер итәргә өйрәнсәк иде. Булганына канәгать булу – сөннәттәндер. Булмаганына канәгать булу – үзе бер гыйлем. Аска карап шөкер ит, өскә карап – гыйбрәт ал, дигәннәр борынгылар. Аллаһ адәм баласына нәрсә кирәген аңа караганда яхшырак белә. Аллаһ Тәгалә насыйп итмәгән икән, димәк, сиңа шулай хәерле. Безгә булганына шөкер итеп, Аллаһ Тәгаләгә биргән нигъмәтләре өчен рәхмәтләр укып, мохтаҗ булганнарын Аллаһтан ялварып яшәргә өйрәнәсе иде!

Чистай Исхакый мирасын барлады

Күренекле якташыбыз, язучы, публицист, сәясәтче, татар милли хәрәкәте эшлеклесе Гаяз Исхакый горурлыгыбыз. Аның безгә калдырган бай мирасы һаман да өйрәнүдә, эзләнүдә әле... Шушы максаттан аның иҗатына багышланган төрле чаралар, укулар, конференцияләр даими рәвештә үткәрелеп тора.

Быел шәһәребезнең 2 нче номерлы гимназиясендә Гаяз Исхакый исемендәге республикакүләм фәнни-гамәли конференция алтынчы тапкыр узды. Әлеге күркәм чараның 110 ел тарихы булган бинада үткәрелүе дә үзе бер горурлык.

Бу юлы да гимназия безне шау-шулы, күңелле тормышы белән каршы алды... Нинди генә күргәзмәләр оештырмаганнар, дөньяның бар оста куллары, бирегә җыелган диярсең! Тырыш, булдыклы директорлары Равилә Гайнетдинова җитәкчелегендә гимназия коллективының милләтебезне үстерү, саклау өстендә тырышып хезмәт куюлары әллә каян сизелеп тора! Без үзебез дә, Гаяз Исхакыйның авылдашлары буларак, буш кул белән килмәдек. Конференция кунакларына күрсәтергә дип, Исхакый тормышын чагылдырган материаллардан күргәзмә ясадык, сөйләр, күрсәтер әйберләребез шактый иде... Музей директоры Рәсимә Ибраһимова белән бергәләп, Исхакый тормышындагы кызыклы вакыйгаларга тукталдык, аның тормыш юлындагы, иҗатындагы борылышларны бәян иттек. Әлеге конференциягә башкалабыздан милләтебезнең йөзек кашлары булган язучылар, фән эшлеклеләре, галимнәр, төрле районнардан мөгаллимәләр, укучылар килү ямь өстенә ямь булды.

Әдәбият галиме, профессор Хатыйп Йосыф улы Миңнегуловны Исхакыйның якташлары аеруча шатланып каршы алды. Үзенең үзенчәлекле, төпле фикерләре, кирәкле теләк-тәкъдимнәре белән рухландырып та, канатландырып та тора ул.

– Гаяз Исхакый кебек башка гаярь кеше тарихыбызда юк. Ул бәхәсләшә, сүзендә нык тора. Менә дигән публицист, тарихчы. Ул үз сүзен теләсә кая әйтә белә. Президентлар белән очраша, алар белән дә сөйләшә белә. Милләте белән чын-чынлап горурлана, татарлыгын кая да дәвам иттерә ул. «Мин татар булып тудым, татар булып яшим», дип милләте өчен көрәшә, – дип сөйли Хатыйп ага Исхакый хакында һәм үзен борчып торган уй-фикерләрен дә белдерә. – Ни кызганыч, Исхакыйдан соңгы вакытта аерылабыз. Әгәр дә без милли юлыбызны дәвам итәргә теләсәк, аны онытырга хакыбыз юк. Без барыбер аны тиешенчә аңлау дәрәҗәсенә күтәрелмәгәнбез әле. Нинди вакытта да милли кыйммәтләребезне югары куярга тиешбез. Җитәкчеләргә дә моны истә тотарга кирәк.

Әдәбият галимнәре Фоат Галимуллин һәм Таһир Гыйләҗев та Исхакый иҗатына бәйле уй-тәэсирләре белән уртаклашты. Ә якташыбыз, Татарстан Дәүләт Советының «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе әгъзасы Алсу Тарханова Яуширмә авылындагы Исхакый музееның контрольга алынуы, анда төзекләндерү эшләре планлаштырылуы хакында хәбәр итте.

Чистай «Ак калфак» оешмасы хатын-кызлары конференциядә катнашып, язучы, журналист Роза Туфитуллованың каһарман шәһәрдәшебез Өммегөлсем Камалованың ерак Төркиядә олуг шәхес Гаяз Исхакый белән аралашкан чорын чагылдырган «Язмыш җиле» романындагы «Чистай кызлары» бүлегеннән бер өзек сәхнәләштерде.

Конференциянең икенче өлешендә төрле районнардан килгән укучылар «Гаяз Исхакый мирасын саклау һәм пропагандалау», «Г.Исхакый һәм аның замандашлары», «Г.Исхакый һәм XXI гасыр башы татар мәдәнияте һәм укучылар иҗаты» дигән секцияләрдә иҗат эшләре белән таныштырдылар. Укучыларның Г.Исхакый иҗатын яктыртуда, аның мирасын саклауда тырышлыклары шатландыра.

Укучыларның барысы да хезмәт куйган. Барысы да мактау сүзләренә лаек. Әмма яхшыларның да яхшыларын билгеләп, җиңүчеләрне ачыклау да мөһим.

Быелгы җиңүчеләр – Чистай шәһәренең 5 нче мәктәбеннән Әмир Җәләлетдинов, каланың 6 нчы мәктәбе укучысы Илья Меркурьев, 5 мәктәбеннән Азалия Мөхәммәтҗанова, Гаделша урта мәктәбеннән Диләрә Хәсәнова һәм Мөслим урта мәктәбеннән Нәзилә Хәсәншина. Алар киләчәктә дә иҗатларын дәвам итсеннәр, татар халкының белемле, тырыш, максатчан, үткәннәрне онытмаучы, киләчәк өчен җан атучы милләтпәрвәрләр булып үссеннәр иде!

Лилия ФӘСХЕТДИНОВА,
Яуширмә мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

26 май – «Санаулы кичләр» (А.Володин). Минвәли Габдуллинның юбилей кичәсе.
27 май – зур залда – «Өйләнәм. tat» (И.Зәйниев). Шәрык клубында – «Сылтама заманга...» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә.
28 май – зур залда – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин). Шәрык клубында – театр оркестрының «Тоторо〵 кунакта» дип исемләнгән концерты.
30 май – «Җәйнең бер көнендә» (Й.Фоссе).
31 май – «Көзге кайтаваз» (Р.Галиуллин).
1 июнь – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
2 июнь – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

26, 27 май – «Анна Каренина» (П.Чайковский).
29, 30 май – Р.Нуриев исемендәге халыкара классик балет фестиваленең гала-концертлары.

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

26 май – «Кияүләр» (Х.Вахит).
28 май – «Аферист» (Н.Исәнбәт).
29 май – Алмаз Ахуновның «Гармун моңнары үтсен йөрәккә...» дип исемләнгән иҗат кичәсе.
30 май – «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов).
31 май – «Яратам! Бетте-китте!»
1 июнь – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
2 июнь – «Хыялый» (С.Әбүзәров).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

26 май – «Корт» (Ф.Галиев).
28 май – 11.00 – «Минем бәхетле көнем» (Е.Гороховская). 18.00 «Матур City» (А.Әхмәтгалиева).
31 май – «Җырлап яшик» (Р.Латыйпов).
1 июнь – «Әлифба» (Л.Әхмәтҗанова, Э.Яруллина, Ф.Насыйбуллин).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

26 май – 13.00 – «Маугли» (Р.Киплинг).15.00 – «Ханума» (А.Цагарели).
27 май – Зур залда – «Конек-Горбунок» (П.Ершов). Кече залда – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).
28 май – Зур залда – «Красная шапочка» (Ш.Перро). Кече залда – «Сертотмас үрдәк» (А.Алиш).
30 май – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар).
31 май – «Конек-Горбунок» (П.Ершов).
1 июнь – 11.00, 13.30 – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әкияте буенча). 12.00 – «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин). 17.00 – «Али-баба и сорок разбойников» (В.Смехов).
2 июнь – 11.00 – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әкияте буенча). 18.30 – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин). 19.00 – «Макбет» (У.Шекспир).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

29 май – «Страсти по Меркьюри» рок-мюзиклы.
30 май – Бер актлы спектакльләр кичәсе.
